учитывать в правоприменительной практике сформулированные Конституционным судом Республики Татарстан подходы относительно обязательности соблюдения законодательно установленного требования к порядку принятия и официального опубликования муниципальных нормативных правовых актов на обоих государственных языках Республики Татарстан (статья 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан»).

4. Согласно Конституции Республики Татарстан каждый в Республике Татарстан имеет право на благоприятную окружающую среду; государство принимает меры по сохранению и оздоровлению окружающей среды, поощряет деятельность, способствующую обеспечению экологического и санитарно-эпидемиологического благополучия (статья 53).

Отношения в сфере взаимодействия общества и природы, возникающие при осуществлении хозяйственной и иной деятельности, связанной с воздействием на природную среду как важнейшую составляющую окружающей среды, урегулированы Федеральным законом от 10 января 2002 года № 7-ФЗ «Об охране окружающей среды». В силу положений статьи 10 указанного Федерального закона управление в области охраны окружающей среды реализуется органами местного самоуправления в соответствии с данным Федеральным законом, другими федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, законами и иными нормативными правовыми актами субъектов Российской Федерации, уставами муниципальных образований и нормативными правовыми актами органов местного самоуправления.

Согласно правовой позиции Конституционного Суда Российской Федерации конституционная обязанность сохранять природу и окружающую среду, бережно относиться к природным богатствам, по смыслу взаимосвязанных положений статей 42 и 58 Конституции Российской Федерации, имеет всеобщий характер и требует от публичной власти принятия мер, направленных на сдерживание загрязнения окружающей среды, предупреждение и минимизацию экологических рисков; в реализации экологической функции государства участвуют и органы местного самоуправления, поскольку обеспечение благоприятных экологических условий жизнедеятельности населения по месту жительства согласуется с основной целью местного самоуправления, заключающейся в удовлетворении основных жизненных потребностей населения муниципальных образований; это предполагает, что на органы местного самоуправления могут быть возложены законом как создание условий для надлежащего исполнения субъектами природопользования своих обязанностей по устранению причиненного природным объектам вреда, так и обеспечение проведения за счет собственных сил и средств мероприятий по ликвидации загрязнения территории муниципального образования отходами, образовавшимися в результате жизнедеятельности населения, если выявленный факт не является следствием невы-

полнения или ненадлежащего выполнения конкретным лицом своих обязанностей, связанных с использованием того или иного земельного участка на территории данного муниципального образования (Постановление от 26 апреля 2016 года № 13-П).

4.1. В силу части 1 статьи 8 Федерального закона от 24 июня 1998 года № 89-ФЗ «Об отходах производства и потребления» (в редакции Федерального закона от 22 августа 2004 года № 122-ФЗ) и пункта 18 части 1 статьи 14 Федерального закона № 131-ФЗ (в редакции, действовавшей до внесения изменений Федеральным законом от 27 мая 2014 года № 136-ФЗ) к полномочиям органов местного самоуправления поселений относилась организация сбора и вывоза бытовых отходов и мусора.

Между тем в связи с принятием Федерального закона от 29 декабря 2014 года № 458-ФЗ «О внесении изменений в Федеральный закон “Об отходах производства и потребления”, отдельные законодательные акты Российской Федерации и признании утратившими силу отдельных законодательных актов (положений законодательных актов) Российской Федерации» (далее — Федеральный закон № 458-ФЗ) указанные положения претерпели изменения и с 1 января 2016 года действуют в новой редакции, согласно которой к вопросам местного значения поселения отнесено только участие в организации деятельности по сбору (в том числе раздельному сбору) и транспортированию твердых коммунальных отходов. С учетом внесенных изменений организация же деятельности по сбору (в том числе раздельному сбору), транспортированию, обработке, утилизации, обезвреживанию и захоронению твердых коммунальных отходов отнесена к полномочиям субъектов Российской Федерации (абзац шестнадцатый статьи 6 Федерального закона «Об отходах производства и потребления»). Данные изменения нашли свое отражение в абзаце тридцать третьем части 1 статьи 8 Экологического кодекса Республики Татарстан и в подпункте 14 пункта 3 статьи 15 Закона Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан».

Как следует из буквального содержания подпункта 14 пункта 1 статьи 7 Устава и пункта 3.7.2 Правил, установленное ими регулирование после 1 января 2016 года не претерпело изменений, предусмотренных нормами федерального и республиканского законодательства, сохранив за органом местного самоуправления Макуловского сельского поселения прежний объем полномочий, а именно организацию сбора и вывоза бытовых отходов и мусора.

В связи с этим подпункт 14 пункта 1 статьи 7 Устава и пункт 3.7.2 Правил не отвечают требованиям положений статьи 24 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан, согласно которым органы местного самоуправления обязаны соблюдать Конституцию и законы Республики Татарстан. Исходя из требований Конституции Республики Татарстан, Совету Макуловского сельского поселения надлежит внести в Устав и Правила соответствующие изменения, вытекающие из положений Федерального закона «Об отходах производства и потребления», Федерального

закона № 131-ФЗ и Закона Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан».

4.2. Согласно части 1 статьи 22 Федерального закона от 30 марта 1999 года № 52-ФЗ «О санитарно-эпидемиологическом благополучии населения» отходы производства и потребления подлежат сбору, накоплению, транспортированию, обработке, утилизации, обезвреживанию, размещению, условия и способы которых должны быть безопасными для здоровья населения и среды обитания и которые должны осуществляться в соответствии с санитарными правилами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации.

В соответствии с абзацем двадцать первым части 1 статьи 2 Федерального закона № 131-ФЗ правила благоустройства территории муниципального образования — муниципальный правовой акт, устанавливающий на основе законодательства Российской Федерации и иных нормативных правовых актов Российской Федерации, а также нормативных правовых актов субъектов Российской Федерации требования к благоустройству и элементам благоустройства территории муниципального образования, перечень мероприятий по благоустройству территории муниципального образования, порядок и периодичность их проведения. Согласно пунктам 1, 10 и 16 части 2 статьи 45.1 указанного Федерального закона правила благоустройства территории муниципального образования могут регулировать вопросы содержания территорий общего пользования и порядка пользования такими территориями; уборки территории муниципального образования; порядка участия граждан и организаций в реализации мероприятий по благоустройству территории муниципального образования.

В рамках приведенных положений федерального законодательства Советом Макуловского сельского поселения утверждены Правила, регламентирующие в том числе перечень требований к уборке территории поселения. По своей правовой природе и целевому назначению Правила направлены на организацию благоустройства территории поселения и приняты органом местного самоуправления в связи с реализацией им полномочий по осуществлению регулирующего, распорядительного, контрольного и иного организационно-властного воздействия, направленного на создание необходимых условий для эффективного обеспечения чистоты и порядка на территории поселения.

Оспариваемый абзац первый пункта 3.7.1 Правил, исходя из своего содержания и смысла, определяет конкретный механизм обращения с ТБО на территории Макуловского сельского поселения, одним из элементов которого выступает обязанность граждан (собственников или нанимателей индивидуальных жилых домов) по заключению договора на вывоз ТБО со специализированной организацией.

Вместе с тем согласно части 1 статьи 421 Гражданского кодекса Российской Федерации граждане и юридические лица свободны в заключении договора; понуждение к заключению договора не допускается, за исключением случаев, когда обязанность за-

ключить договор предусмотрена данным Кодексом, законом или добровольно принятым обязательством. На момент принятия оспариваемой нормы Правил ни Гражданский кодекс Российской Федерации, ни Жилищный кодекс Российской Федерации, ни федеральные законы, устанавливающие перечень полномочий органов местного самоуправления, а также права, обязанности и ответственность граждан при решении вопросов, связанных с оказанием услуг по вывозу бытовых отходов, ни Правила предоставления услуг по вывозу твердых и жидких бытовых отходов, утвержденные постановлением Правительства Российской Федерации от 10 февраля 1997 года № 155, не содержали положений императивного характера, обязывающих граждан заключать договоры на сбор, хранение и вывоз бытовых отходов и мусора со специализированными организациями.

В настоящее время обязанность собственника жилого дома или части жилого дома обеспечивать обращение с твердыми коммунальными отходами путем заключения соответствующего договора закреплена в части 5 статьи 30 Жилищного кодекса Российской Федерации. Однако данная норма, введенная Федеральным законом № 458-ФЗ, вступила в силу только с 1 января 2016 года. При этом в соответствии с указанным положением Кодекса гражданин обязан заключить такой договор с региональным оператором по обращению с твердыми коммунальными отходами (далее — региональный оператор).

Согласно абзацу двадцать седьмому статьи 1 Федерального закона «Об отходах производства и потребления» региональный оператор — оператор по обращению с твердыми коммунальными отходами — юридическое лицо, которое обязано заключить договор на оказание услуг по обращению с твердыми коммунальными отходами с собственником твердых коммунальных отходов, которые образуются и места накопления которых находятся в зоне деятельности регионального оператора. Статус регионального оператора в силу части 4 статьи 24.6 названного Федерального закона может быть присвоен юридическому лицу только на основании конкурсного отбора, проводимого уполномоченным органом исполнительной власти субъекта Российской Федерации в порядке, установленном Правительством Российской Федерации, а также после определения зоны его деятельности.

В Республике Татарстан механизм определения регионального оператора нашел отражение в Экологическом кодексе Республики Татарстан и принятых на его основании подзаконных актах Кабинета Министров Республики Татарстан.

Тем самым анализ буквального содержания оспариваемого пункта 3.7.1 Правил в его взаимосвязи с нормами федерального и республиканского законодательства, действовавшими как до 1 января 2016 года, так и после 1 января 2016 года, позволяет сделать вывод, что предусмотренное в нем правовое регулирование как в части установления обязанности собственников или нанимателей индивидуальных жилых домов заключать договоры со специализированными организациями, так и в части определе-

ния специализированных организаций, не отвечающих предусмотренным законодательством требованиям, свидетельствует о превышении Советом Макуловского сельского поселения предоставленных ему в этой сфере полномочий и, следовательно, приводит к необоснованному ограничению конституционных прав и свобод граждан.

Вместе с тем Конституция Российской Федерации допускает ограничение прав и свобод человека и гражданина только федеральным законом и только в той мере, в какой это необходимо в целях защиты основ конституционного строя, нравственности, здоровья, прав и законных интересов других лиц, обеспечения обороны страны и безопасности государства (статья 55, часть 3).

Данным конституционным предписаниям корреспондирует пункт 2 статьи 29 Всеобщей декларации прав человека, в силу которого при осуществлении своих прав и свобод каждый человек должен подвергаться только таким ограничениям, какие установлены законом исключительно с целью обеспечения должного признания и уважения прав и свобод других и удовлетворения справедливых требований морали, общественного порядка и общего благосостояния в демократическом обществе. Аналогичные положения содержатся в пункте 3 статьи 12 Международного пакта о гражданских и политических правах и в статье 4 Международного пакта об экономических, социальных и культурных правах.

Следовательно, возложение на граждан актом органа местного самоуправления обязанностей и обременений, превышающих по своему уровню те, которые определены федеральным законом, недопустимо.

Такой вывод корреспондирует позиции Конституционного Суда Российской Федерации, согласно которой субъект Российской Федерации вправе наряду с основными гарантиями прав граждан, закрепленными федеральным законом, установить в своем законе дополнительные гарантии этих прав, направленные на их конкретизацию, создание дополнительных механизмов их реализации, с учетом региональных особенностей (условий) и с соблюдением конституционных требований о непротиворечии законов субъектов Российской Федерации федеральным законам и о недопустимости ограничения прав и свобод человека и гражданина в форме иной, нежели федеральный закон; во всяком случае, осуществляя такое регулирование, законодатель субъекта Российской Федерации не должен вводить процедуры и условия, которые искажают само существо тех или иных конституционных прав, и снижать уровень их федеральных гарантий, закрепленных на основе Конституции Российской Федерации федеральными законами, а также вводить какие-либо ограничения конституционных прав и свобод, поскольку таковые — в определенных Конституцией Российской Федерации целях и пределах — может устанавливать только федеральный законодатель (Постановление от 18 июля 2012 года № 19-П).

При таких обстоятельствах Конституционный суд Республи-

ки Татарстан приходит к выводу, что абзац первый пункта 3.7.1 Правил не соответствует Конституции Республики Татарстан, ее статьям 24 (часть вторая), 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 58 (часть вторая).

На основании изложенного, руководствуясь статьей 6, частями первой и второй статьи 66, статьями 67, 68, 69, 71, 73 и 104 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**постановил:**

1. Признать Устав Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан, принятый решением Макуловского Совета местного самоуправления от 30 июня 2005 года № 7, Правила благоустройства территории Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан, утвержденные решением Совета Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан от 16 декабря 2015 года № 6-35, соответствующими Конституции Республики Татарстан по порядку их принятия и официального опубликования.

2. Признать статью 75 Устава Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан, принятого решением Макуловского Совета местного самоуправления от 30 июня 2005 года № 7, соответствующей Конституции Республики Татарстан.

3. Признать подпункт 14 пункта 1 статьи 7 Устава Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан, принятого решением Макуловского Совета местного самоуправления от 30 июня 2005 года № 7, и пункт 3.7.2 Правил благоустройства территории Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан, утвержденных решением Совета Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан от 16 декабря 2015 года № 6-35, не соответствующими Конституции Республики Татарстан, ее статье 24 (часть вторая).

4. Признать абзац первый пункта 3.7.1 Правил благоустройства территории Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан, утвержденных решением Совета Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан от 16 декабря 2015 года № 6-35, не соответствующим Конституции Республики Татарстан, ее статьям 24 (часть вторая), 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 58 (часть вторая).

5. Совету Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан — исходя из требований Конституции Республики Татарстан и с учетом основанных на этих требованиях правовых позиций Конституционного суда Республики Татарстан, выраженных в настоящем Поста-

новлении, — внести в действующее на территории Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан правовое регулирование необходимые изменения, вытекающие из настоящего Постановления.

Впредь до внесения надлежащих изменений правоприменителям следует руководствоваться правовыми позициями Конституционного суда Республики Татарстан, изложенными в настоящем Постановлении.

6. Настоящее Постановление окончательно, не подлежит обжалованию, вступает в силу немедленно после его провозглашения, действует непосредственно и не требует подтверждения другими органами и должностными лицами.

7. Согласно статье 72 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» настоящее Постановление подлежит незамедлительному опубликованию в газетах «Ватаным Татарстан» и «Республика Татарстан». Постановление должно быть опубликовано также в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 79-П

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ИСЕМЕ БЕЛӘН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**гражданка В.М. Омарова шикаятенә бәйле рәвештә Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасы һәм 75 статьясының, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 3.7.1 пунктындагы беренче абзацы һәм 3.7.2 пунктының, шулай ук тулысынча аталган Устав һәм Кагыйдәләрнең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

2018 ел
20 июнь
Казан шәһәре

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасы һәм 75 статьясының, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 3.7.1 пунктындагы беренче абзацы һәм 3.7.2 пунктының, шулай ук кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча тулысынча аталган Устав һәм Кагыйдәләрнең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка В.М. Омарова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Э.М. Мостафина мәгълүматын, яклар — гражданка В.М. Омарова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы Н.В. Пичугина, суд утырышына Татарстан Республи-

касы Конституция суды инициативасы буенча чакырылган белгечләр — Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Россия Федерациясе субъекты норматив хокукый актлары һәм федераль регистрны алып бару, муниципаль берәмлекләр реестрын алып бару, муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү һәм аларның реестрын алып бару мәсьәләләре бүлеге башлыгы Р.Н. Рәхимов, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының калдыклар белән эш итү бүлеге әйдәүче консультанты Л.З. Хәйретдинова, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының җирле үзидарә өлкәсендә норматив хокукый эш һәм муниципаль регистрны алып бару бүлеге башлыгы Р.У. Гарипов аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Е.Е. Шехматова, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминский, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы А.Г. Бартенев чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка В.М. Омарова Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының (алга таба шулай ук — Устав) 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасы һәм 75 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының (алга таба шулай ук — Макыл авыл җирлеге Советы) 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 3.7.1 пунктындагы беренче абзацы һәм 3.7.2 пункты, шулай ук кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча тулысын-

ча аталган Устав һәм Кагыйдәләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Уставның 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасы буенча көнкүреш калдыкларын һәм чүпне җыю һәм чыгаруны оештыру Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең (алга таба шулай ук — Макыл авыл җирлеге) җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә карый.

Уставның 75 статьясы Макыл авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын бастырып чыгару, халыкка җиткерү һәм аларның үз көченә керү тәртибен билгели.

Кагыйдәләрнең 3.7.1 пунктындагы беренче абзацы нигезендә гражданнар (индивидуаль торак йортларның милекчеләре яки яллаучылары), эшчәнлекләрен авыл җирлеге территориясендә башкаручы шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар каты көнкүреш калдыкларын (алга таба — ККК), төзелеш чүбен расланган санитар нормалар һәм кагыйдәләр, туплау нормалары буенча чыгаруны калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, транспорт белән ташу, урнаштыру эшчәнлеген башкаручы оешмалар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә оештыралар. Шул ук вакытта КККны чыгаруга шартнамә төзү барлык юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр өчен мәҗбүри.

Кагыйдәләрнең 3.7.2 пункты җирлек территориясендә көнкүреш калдыкларын җыю, чыгаруны оештыруны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетына (алга таба — Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты) йөкли.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка В.М. Омарова — Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Рус Макылы авылындагы торак йорт милекчесе. Әлеге җирлек территориясендә калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, транспорт белән ташу, урнаштыру эшчәнлеген «ЭкоАвтоТрейд» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба —«ЭкоАвтоТрейд» ҖЧҖ) башкара. 2015 елның июнендә мөрәҗәгать итүчегә беренче тапкыр КККны җыю, чыгару, утильләштерү хезмәте өчен түләүгә исәп-фактура килгән. Моны законсыз дип санап, ул Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетына мөрәҗәгать иткән, аның җавабында күрсәтелгән хезмәт өчен түләүнең кертелергә тиешлеге хәбәр ителгән. 2015 елның 4 сентябрендә (ягъни исәп-хисап кәгазьләре берничә тапкыр килгәннән соң) «ЭкоАвтоТрейд» ҖЧҖ КККны чыгару һәм урнаштыру хезмәтен күрсәтүгә шартнамәне «Волжская новь» газетасында гавами оферта буларак бастырып чыгарган.

2016 елның гыйнварында шикаять итүче «ЭкоАвтоТрейд» ҖЧҖга, аның белән шартнамә төземәгәнгә һәм күрсәтелгән хезмәттән файдаланмаганга күрә, әлеге хезмәт буенча түләүне хисаплау һәм алуны туктату таләбе белән мөрәҗәгать иткән, ләкин аның таләпләре игътибарсыз калдырылган.

Соңыннан гражданка В.М. Омарова «ЭкоАвтоТрейд» ҖЧҖга

ККНы җыю, чыгару, утильләштерү хезмәте өчен түләүне хисаплау һәм алуны законсыз дип тану, әлеге оешмага күрсәтелгән коммуналь хезмәт өчен түләүне хисаплауны туктату бурычын йөкләү һәм мораль зыянны каплау турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать иткән.

Татарстан Республикасы Югары Ослан район судының Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган карары белән дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән гражданка В.М. Омаровага баш тартылган. Татарстан Республикасы Югары суды судьясы билгеләмәсе белән кассация шикаятен Татарстан Республикасы Югары судының кассация инстанциясе утырышында карауга тапшырудан шулай ук баш тартылган.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, гомуми юрисдикция судлары карарлары, аерым алганда, әлеге нигезләмәгә таянган: гражданнар (индивидуаль торак йортларның милекчеләре яки яллаучылары) ККНы, төзелеш чүбен расланган санитар нормалар һәм кагыйдәләр, туплау нормалары буенча чыгаруны калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, транспорт белән ташу, урнаштыру эшчәнлеген башкаручы оешмалар (алга таба шулай ук — махсуслаштырылган оешма) белән төзелгән шартнамәләр нигезендә оештыралар. Ләкин гражданка В.М. Омарова санаганча, Кагыйдәләрнең 3.7.1 пунктының беренче абзацында билгеләнгән гражданнар (индивидуаль торак йортларның милекчеләре яки яллаучылары) тарафыннан махсуслаштырылган оешмалар белән шартнамәләр төзү тиешлеге шартнамә иреге принцибын боза, аның буенча федераль законнарда яисә ирекле кабул ителгән йөкләмәдә шартнамә төзү бурычы каралган очраклардан тыш, шартнамә төзергә мәҗбүр итү тыела.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук күрсәткәнчә, җирле үзидарәне оештыру мәсьәләләрен җайга сала торган федераль законнарда җирле үзидарә органнарының карала торган өлкәдәге вәкаләтләре күләмен билгеләү өлешендә җитди үзгәрешләр була, алар хәзерге вакытта Уставта, шул исәптән аның 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында һәм Кагыйдәләрдә, шул исәптән 3.7.2 пунктында исәпкә алынмаган. Шуңа бәйле рәвештә гражданка В.М. Омарова күрсәтелгән нормалар аның хосусый милеккә конституциячел хокукын бозалар, шулай ук формаль тигезлек конституциячел принцибы белән ярашмыйлар, дип саный.

Моннан тыш, гражданка В.М. Омарова шуңа игътибар итә: Устав та, Кагыйдәләр дә татар телендә басылып чыкмаган, бу исә, аның фикеренчә, Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең тигезлеге конституциячел принцибын, шулай ук тигезлек һәм гаделлек гомумхокук һәм конституциячел принципларын боза. Мондый бозулар, ул уйлаганча, шуңа бәйле: Уставның 75 статьясы, Макыл авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын бастырып чыгару, халыкка җиткерү һәм аларның үз көченә керү тәртибен билгеләп, кеше һәм граждан хо-

куклары, ирекләре һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бастырып чыгару тиешлеген беркетми.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук шуны билгеле: кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча тулысынча Устав аның конституциячел хокукларын боза, чөнки ул Макыл авыл җирлегенең рәсми сайтында аның белән расланган тиешле реквизитлары булган карарсыз басылып чыккан.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка В.М. Омарова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасын һәм 75 статьясын, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 3.7.1 пунктындагы беренче абзацын һәм 3.7.2 пунктын, шулай ук тулысынча аталган Уставны һәм Кагыйдәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенең 8, 10, 24 (икенче һәм өченче өлешләр), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49, 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә Татарстан Республикасында дәүләт телләре — тигез хокуклы татар һәм рус телләре; җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасының дәүләт телләре бертигез нигезләрдә кулланыла; Татарстан Республикасында җирле үзидарә танылa һәм гарантияләнә; җирле үзидарә үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль; җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; хосусый милек хокукы закон белән саклана; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше һәм 68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда фактагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала; бары

тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә. Карар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, түбәндәгеләр әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар:

— Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставы кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча тулысынча, чөнки ул Макыл авыл җирлегенең рәсми сайтында аның белән расланган тиешле реквизитлары булган карарсыз басылып чыккан;

— Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре тулысынча, чөнки алар Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телендә басылып чыкмаган;

— Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 75 статьясы, чөнки ул, Макыл авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын бастырып чыгару, халыкка җиткерү һәм аларның үз көченә керү тәртибен билгеләп, кеше һәм гражданхокуклары, ирекләре һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бастырып чыгару тиешлеген беркетми;

— Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 3.7.1 пунктындагы беренче абзацы һәм 3.7.2 пункты.

2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 10, 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьялары нигезендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә таныла һәм гарантияләнә, ул үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль һәм, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның хәл итүен тәэмин итә. Шундый ук нигезләмәләр Рос-

сия Федерациясе Конституциясенең 12, 130 (1 өлеш) һәм 132 (1 өлеш) статьяларында да беркетелгән.

Җирле үзидарә оештыруның гомуми хокукый, оештыру һәм икътисади принципларын билгели торган «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба — 131-ФЗ номерлы Федераль закон) белән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында җирлекләрнең җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр, өстәмәләр кертү һәм муниципаль хокукый актлар бастырып чыгару вәкаләтләренә ия дип каралган (17 статьяның 1 өлешендәге 1 пункты). Аталган Федераль законның 43 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты һәм 44 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләре нигезләмәләре буенча муниципаль берәмлек уставы муниципаль хокукый актлар системасына керә, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителә, җирле үзидарә оештыру һәм аның эшчәнлеге мәсьәләләрен җайга сала һәм шул исәптән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеген, шулай ук муниципаль хокукый актларның төрләрен, аларны кабул итү (чыгару), рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибен билгели. Тиңдәш нормалар шулай ук «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлешенең 2, 6 пунктлары һәм 3 өлеше белән каралган.

Шулай итеп, Уставны кабул итеп һәм аның дәгъвалана торган нормаларында Макыл авыл җирлеге карамагында булган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеген, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары кабул итә торган муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибен беркетеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы — Макыл авыл җирлеге Советы — үзенә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә эш иткән.

131-ФЗ номерлы Федераль законның (2011 елның 30 ноябрендәге 361-ФЗ номерлы һәм 2014 елның 27 маендагы 136-ФЗ номерлы федераль законнар редакциясендә) 14 статьясындагы 1 өлешенең 19 пунктыннан һәм 3 өлешеннән чыгып, авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә җирлек территориясен төзекләндерү белән бәрәттән әлеге территорияне төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, шулай ук биналар (алардагы урыннар) һәм корылмалар милекчеләренең янәшә урнашкан территорияләрне төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү керә. Эчтәлеге буенча тиңдәш нигезләмәләр «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының (2015 елның 3 ноябрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 15 статьясындагы 3 өлешенең 9 пунктында беркетелгән.

Федераль һәм республика законнарының күрсәтелгән нигезләмәләренә күрә Уставта Макыл авыл җирлеге Советы вәкаләтләренә шул исәптән әлеге җирлек территориясендә гомуммәҗ-

бүри кагыйдәләр билгеләү вәкаләте кертелгән (32 статьясының 1 өлешендәге 2 пункты). Уставның китерелгән нигезләмәләрен үтәү йөзеннән Макыл авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре расланган.

Шулай итеп, Устав һәм Кагыйдәләрне кабул итеп, Макыл авыл җирлеге Советы федераль һәм республика законнары белән үзенә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьялары нигезләмәләренә нигезләнгән вәкаләтләрен законлы рәвештә гамәлгә ашырган.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясының үзара бәйле нигезләмәләре буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы Конституциясенә шул исәптән аларны кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча туры килү-килмәвен билгели.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (өченче өлеш) һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 15 статьясы (3 өлеш) нигезендә кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, дәүләт исеменнән норматив хокукый актны гавами хакимиятнең компетентлы органы тарафыннан халыкка җиткерү таләбе хокукый билгеләнешнең гомумтанылган принцибына бәйле, аның нигезендә дәүләтнең һәм шәхеснең мөнәсәбәтләре билгеләнә һәм җәмәгатьчелеккә хәбәр итү әлеге норматив хокукый актның кабул ителүе һәм бәян ителгән тулы текстының гамәлгә кертелергә тиешлеген аңлата. Шул очракта гына аның гамәлдә булуы кагыла торган затларга законны белмәү аны бозган өчен җаваплылыктан азат итми дигән гомумхокукый презумпция кагыла. Норматив хокукый актның гамәлдә булу яисә булмавына карата билгесезлек аны саклауда, үтәүдә һәм куллануда бертөрлелекне тәэмин итә алмый һәм, димәк, хокук куллану практикасында каршылык китереп чыгара, аны зыянлы максатта һәм башбаштакланып файдалану мөмкинлеген тудыра, конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен киметә, тигезлек һәм хокук өстенлеге принципларын бозуга китерә (2012 елның 27 мартындагы 8-П номерлы Карар).

Татарстан Республикасы Конституция суды бу конституциячел күрсәтмә кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен яклау гарантияләренең берсе булып тора һәм ул императив характерга ия дип берничә тапкыр билгеләп үтте (2006 елның 7 мартындагы 19-П номерлы һәм 2012 елның 21 февралендәге 47-П номерлы карарлар).

3.1. Уставны кабул итү моментына аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 ста-

тьясындагы 8 өлеше нигезләмәләре белән җайга салынган булган, алар нигезендә муниципаль берәмлек уставы дәүләт теркәве узганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш булган һәм ул рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә кергән. Тиңдәш нигезләмәләр «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 7 өлешендә дә беркетелгән булган.

Эш материалларыннан, дәгъвалана торган муниципаль хокукый актны чыгарган орган вәкиле, шулай ук суд утырышына чакырылган белгеч чыгышларыннан шул аңлашыла: Устав Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән һәм дәүләт теркәве узганнан соң, әлеге карарның 2 пункты буенча, аның текстын махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелгән, алар шул вакытта гамәлдә булган хокукый җайга салу нигезендә Макыл авыл җирлеге территориясендә кабул ителә торган норматив хокукый актларның рәсми басылып чыгу чыганаклары булып саналган.

Хәзерге вакытта Устав Макыл авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылган, ә Уставның титул битенең график сурәтендә законнарда каралган реквизитлары (исеме, имзалаган көне, теркәү номеры, хокукый актны имзалаган вазыйфаи зат исеме) бар.

Мондый шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды шундый нәтиҗәгә килә: Устав рәсми рәвештә басылып чыккан, аның эчтәлеге гражданнар игътибарына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән һәм шуның белән Устав рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясына (өченче өлеш) туры килә.

3.2. Гавами хакимият органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибенә кагылышлы мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституция судының тикшерү предметы булган иде инде, ул 2017 елның 23 июнендәге 74-П номерлы карарында аеруча шуны ассызыклады: Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең тигезлеге конституциячел принцибы кысаларында гавами хакимият органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы дәүләт телләренең икесендә дә рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибен һәм тиешле срокларны үтәү мәҗбүри.

Эш материалларыннан һәм дәгъвалана торган муниципаль хокукый актларны чыгарган орган вәкиле чыгышыннан аңлашылганча, әлеге муниципаль хокукый актлар рәсми рәвештә бары тик рус телендә генә басылып чыккан. Татар телендә исә дәгъвалана торган актлар кабул ителмәгән һәм рәсми рәвештә басылып чыкмаган.

Шулай итеп, Уставны һәм Кагыйдәләрне кабул иткәндә җирле

үзидарә органнары актлары татар телендә дә, рус телендә дә кабул ителергә тиеш дигән таләпне бозуга юл куелган. Әлеге таләпне үтәү «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы икенче өлеше нигезләмәләре белән каралган һәм турыдан-туры Татарстан Республикасы Конституциясенең җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасының дәүләт телләре бертигез нигезләрдә кулланыла дип билгеләгән нормаларыннан (8 статья) килеп чыга.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды инде күрсәткәнчә, норматив хокукый акт текстын Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә генә рәсми рәвештә бастырып чыгару үзеннән-үзе аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип таныр өчен җитәрлек нигез дип санала алмый, чөнки бу гражданнарга аларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы карала торган норматив хокукый актның эчтәлеге белән танышу мөмкинлеген тормышка ашыруда объектив рәвештә киртәләр тудырмый (2017 елның 3 октябрендәге 75-П номерлы карар).

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә Уставны һәм Кагыйдәләрне кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала, чөнки башкача бу Макыл авыл җирлеге Советы кабул иткән бүтән норматив хокукый актларның конституциячеллеген генә түгел, ә әлеге авыл җирлеге Уставының асылы буенча оештыру акты буларак, шулай ук Кагыйдәләр белән гомумән билгеләнгән бердәм һәм мәҗбүри таләпләрнең законлы булуын да шик астына куярга мөмкинлек бирер иде. Мондый нәтиҗә конституциячел суд эшләрен башкару максатларына каршы килер иде, алар Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы буенча Татарстан Республикасының конституциячел корылышын, кешенең төп хокукларын һәм ирекләрен яклаудан, Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасының хокукый системасында өстенлеген һәм аның бөтен территориясендә турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итүдән гыйбарәт.

Моның белән Макыл авыл җирлеге Советыннан — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының шул исәптән әлеге Карарда да бәян ителгән хокукый позицияләрен исәпкә алып — карала торган муниципаль хокукый актларны Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телендә кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару бурычы төшерелми.

3.3. Мөрәҗәгать итүченең Макыл авыл җирлеге Уставының 75 статьясы нигезләмәләренең, Макыл авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын бастырып чыгару, халыкка җиткерү һәм аларның үз көченә керү тәртибен билгеләп, аларда кеше

һәм граждан хокуклары, ирекләре һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бастырып чыгару тиешлеген регламентлаштыра торган нигезләмәләр булмаган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәве турындагы позициясенә килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгене билгеләп үтә.

Россия Федерациясе Конституциясе буенча республикалар үз дәүләт телләрен билгеләргә хокуклы; алар республикаларның җирле үзидарә органнарында Россия Федерациясенең дәүләт теле белән беррәттән кулланыла (68 статья, 2 өлеш).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 статьясы буенча Татарстан Республикасында дәүләт телләре — тигез хокуклы татар һәм рус телләре; җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасының дәүләт телләре бертигез нигезләрдә кулланыла. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясындагы икенче өлеше нигезендә җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш. Әлеге конституциячел нигезләмәләргә «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы икенче өлеше нормалары туры килә.

Димәк, шундый таләпнең турыдан-туры Уставның 75 статьясында булмавы үзеннән-үзе норматив хокукый актны ике дәүләт телендә бастырып чыгару мәҗбүри булган закон таләбен үтәмәү мөмкинлегенә юл куймый. Шулай итеп, Уставның 75 статьясындагы дәгъвалана торган нигезләмәләр кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең хокукларын ул күрсәткән аспектта юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 һәм 28 (беренче өлеш) статьяларына каршы килмиләр.

Уставның 75 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану Макыл авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибен хокукый җайга салуны камилләштерүгә комачауламый. Шуңа бәйле рәвештә Уставка Макыл авыл җирлеге территориясендә кабул ителә торган норматив хокукый актлар рәсми рәвештә Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә басылып чыга дигән төгәл күрсәтмә билгели торган нигезләмәләр кертү татар телен Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак аның бөтен территориясендә куллану мәсьәләсендә ачыклык, билгелелек һәм мәгънә берлеге булуга, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллануга гражданнарның законнарда беркетелгән хокукларын, татар тел культурасын яклауны һәм үстерүне тәэмин итүгә ярдәм итәр иде.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары муниципаль норматив хокукый актларны Та-

тарстан Республикасының ике дәүләт телендә кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибенә карата законда билгеләнгән таләпне үтәүнең мәҗбүрилеге хакында Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан булдырылган алымнарны хокук куллану практикасында исәпкә алырга тиеш дип тагын ассызыклый («Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 73 статьясы).

4. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасында һәркем уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокуклы; дәүләт әйләнә-тирә мохитне саклап калу һәм савыктыру чараларын күрә, экология һәм санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүгә булыша торган эшчәнлекне хуплый (53 статья).

Әйләнә-тирә мохитнең иң мөһим өлеше булган табигать мохитенә йогынты ясау белән бәйле хуҗалык эшчәнлегендә һәм башка эшчәнлектә барлыкка килә торган җәмгыять һәм табигать бәйләнешләре өлкәсендәге мөнәсәбәтләр «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салынган. Күрсәтелгән Федераль законның 10 статьясы нигезләмәләре буенча әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль берәмлекләр уставлары һәм җирле үзидарә органнары норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе нигезендә табигатьне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, табигый байлыкларга сакчыл мөнәсәбәттә булу конституциячел бурычы, Россия Федерациясе Конституциясенең 42 һәм 58 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләре мәгънәсе буенча, гомуми характерга ия һәм гавами хакимияттән әйләнә-тирә мохитне пычратуны туктатуга, экологик хәтәрләрне кисәтүгә һәм минимальләштерүгә юнәлгән чаралар кабул итүне таләп итә; дәүләтнең экологик функциясен гамәлгә ашыруда җирле үзидарә органнары да катнаша, чөнки халыкның яшәү урыныңдагы көнкүреше өчен уңай экологик шартлар тәэмин итү җирле үзидарәнең төп максаты белән яраша, ул муниципаль берәмлекләр халкының төп яшәү ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән гыйбарәт; бу шуны күздә тота: закон белән җирле үзидарә органнарына табигатьтән файдаланучы субъектларның табигать объектларына салынган зыянны бетерү бурычларын тиешенчә үтәве өчен шартлар тудыру да, шулай ук үз көчләре һәм чаралары хисабына халыкның көнкүреше нәтиҗәсендә барлыкка килгән калдыклар белән муниципаль берәмлек территориясе пычрануны юкка чыгару буенча чаралар үткәрүне тәэмин итү дә йөкләнгән, әгәр ачыкланган факт конкрет зат тарафыннан әлеге муниципаль берәмлек территориясендә теге яки бу җир кишәрлеген куллану белән

бәйле бурычларын үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү нәтиҗәсе булмаса (2016 елның 26 апрелендәге 13-П номерлы Карар).

4.1. «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның (2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 8 статьясындагы 1 өлеше һәм 131-ФЗ номерлы Федераль законның (2014 елның 27 маендагы 136-ФЗ номерлы Федераль закон белән үзгәрешләр кертелгәнче гамәлдә булган редакциясендә) 14 статьясындагы 1 өлешенең 18 пункты нигезендә җирлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә көнкүреш калдыкларын һәм чүпне җыю һәм чыгаруны оештыру кергән.

Шул ук вакытта «“Җитештерү һәм куллану калдыклары турында” Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары (закон актлары нигезләмәләре) үз көчен югалткан дип тану турында» 2014 елның 29 декабрендәге 458-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба — 458-ФЗ номерлы Федераль закон) кабул ителү сәбәпле күрсәтелгән нигезләмәләр үзгәрешләр кичерә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан яңа редакциядә гамәлдә, аның нигезендә җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю) һәм транспорт белән ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу гына керә. Кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю), транспорт белән ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү эшчәнлеген оештыру исә Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә кертелгән («Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законның 6 статьясындагы уналтынчы абзацы). Әлеге үзгәрешләр Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясындагы 1 өлешенең утыз өченче абзацында һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 пунктының 14 пунктчасында чагылыш тапкан.

Уставның 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасы һәм Кагыйдәләрнең 3.7.2 пунктының сүзгә-сүз эчтәлегеннән аңлашылганча, алар тарафыннан билгеләнгән җайга салу 2016 елның 1 гыйнварыннан соң, Макыл авыл җирлегенең җирле үзидарә органы вәкаләтләренең элеккеге күләмен, атап әйткәндә, көнкүреш калдыкларын һәм чүпне җыю һәм чыгаруны оештыруны саклап, федераль һәм республика законнары нормалары белән каралган үзгәрешләр кичерми.

Шуңа бәйле рәвештә Уставның 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасы һәм Кагыйдәләрнең 3.7.2 пункты Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (икенче өлеш) нигезләмәләре таләпләренә җавап бирми, алар нигезендә җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш. Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып, Макыл авыл җирлеге Советына Уставка һәм Кагыйдәләргә «Җитештерү һәм куллану калдыкла-

ры турында» Федераль закон, 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләренә таянган тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

4.2. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 1 өлеше нигезендә җитештерү һәм куллану калдыклары җыелырга, тупланырга, транспорт белән ташылырга, эшкәртелергә, утильләштерелергә, зарарсызландырылырга, урнаштырылырга тиеш, аларның шартлары һәм ысуллары халык сәламәтлеге һәм яшәү тирәлеге өчен куркынычсыз булырга тиеш һәм алар санитария кагыйдәләре һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең егерме беренче абзацы буенча мунципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре — Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерүгә һәм төзекләндерү элементларына таләпләр, муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү чаралары исемлеген, аларны уздыру тәртибе һәм ешлыгын билгели торган муниципаль хокукый акт. Күрсәтелгән Федераль законның 45.1 статьясындагы 2 өлешенең 1, 10 һәм 16 пунктлары буенча муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре гомуми кулланылыштагы территорияләрне карап тоту һәм шундый территорияләрдән файдалану тәртибе; муниципаль берәмлек территориясен җыештыру; гражданнар һәм оешмаларның муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруда катнашу тәртибе мәсьәләләрен җайга салырга мөмкин.

Китерелгән федераль законнар нигезләмәләре кысаларында Макыл авыл җирлеге Советы тарафыннан шул исәптән җирлек территориясен җыештыруга таләпләр исемлеген регламентлаштыра торган Кагыйдәләр расланган. Хокукый табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча Кагыйдәләр җирлек территориясен төзекләндерүне оештыруга юнәлдерелгән һәм җирле үзидарә органы тарафыннан җирлек территориясендә чисталык һәм тәртипне нәтиҗәле тәэмин итү өчен тиешле шартлар тудыруга юнәлгән җайга салучы, күрсәтмә бирүче, контрольдә тотучы һәм башка оештыру-боерулы йогынты ясау буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле кабул ителгән.

Кагыйдәләрнең 3.7.1 пунктының дәгъвалана торган абзацы, эчтәлеге һәм мәгънәсеннән чыгып, Макыл авыл җирлеге территориясендә ККК белән эш итүнең конкрет механизмын билгели, аның бер элементы булып гражданнарның (индивидуаль торак йортларның милекчеләре яки яллаучыларының) махсуслаштырылган оешма белән KKKны чыгаруга шартнамә төзү бурычы тора.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Граждан кодексының 421 статьясындагы 1 өлеше буенча гражданнар һәм юридик затлар шартнамә төзүдә ирекле; әлеге Кодекс, закон яисә ирекле кабул ителгән йөкләмә белән шартнамә төзү бурычы каралган очраклардан тыш, шартнамә төзергә мәҗбүр итү тыела. Кагыйдәләрнең дәгъвалана торган нормасын кабул итү моментына Россия Федерациясе Граждан кодексында да, Россия Федерациясе Торак кодексында да, җирле үзидарә органнары вәкаләтләре исемләген, шулай ук гражданнарның көнкүреш калдыкларын чыгару хезмәтләрен күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне хәл иткәндәге хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгын билгели торган федераль законнарда да, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1997 елның 10 февралендәге 155 номерлы карары белән расланган Каты һәм сыек көнкүреш калдыкларын чыгару хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләрендә дә гражданнарны махсуслаштырылган оешмалар белән көнкүреш калдыкларын һәм чүпне җыю, саклау һәм чыгаруга шартнамәләр төзергә мәҗбүр итә торган императив характердагы нигезләмәләр юк иде.

Хәзерге вакытта торак йорт яки торак йорт өлеше милекчесенең каты коммуналь калдыклар белән эш итүне тиешле шартнамә төзү юлы белән тәэмин итү бурычы Россия Федерациясе Торак кодексының 30 статьясындагы 5 өлешендә беркетелгән. Ләкин 458-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән әлеге норма 2016 елның 1 гыйнварыннан гына үз көченә керә. Шул ук вакытта Кодексның күрсәтелгән нигезләмәсе буенча граждан андый шартнамәне каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ оператор (алга таба — региональ оператор) белән төзергә тиеш.

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законның 1 статьясындагы егерме җиденче абзацы нигезендә региональ оператор — каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча оператор — региональ оператор эшчәнлеге зонасында барлыкка килә торган һәм туплану урыннары шунда булган каты коммуналь калдыклар милекчесе белән каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтүгә шартнамә төзергә тиеш булган юридик зат. Региональ оператор статусы аталган Федераль законның 24.6 статьясындагы 4 өлеше буенча юридик затка Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә үткәрелә торган конкурслы сайлап алу нигезендә генә, шулай ук аның эшчәнлек зонасын билгеләгәннән соң бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасында региональ операторны билгеләү механизмы Татарстан Республикасы Экология кодексында һәм аның нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителгән законга буйсынулы актларда чагылыш тапкан.

Шуның белән Кагыйдәләрнең дәгъвалана торган 3.7.1 пунктының сүзгә-сүз эчтәлеген федераль һәм республика законнарының 2016 елның 1 гыйнварына кадәр дә, 2016 елның

1 гыйнварыннан соң да гамәлдә булган нормалары белән үзара бәйләнештә анализлау шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: анда каралган хокукый җайга салу индивидуаль торак йортлар милекчеләре яки яллаучыларының махсуслаштырылган оешмалар белән шартнамәләр төзү бурычын билгеләү өлешендә дә, законнар белән каралган таләпләргә җавап бирми торган махсуслаштырылган оешмаларны билгеләү өлешендә дә Макыл авыл җирлеге Советының әлеге өлкәдә аңа бирелгән вәкаләтләрдән читкә чыгуын күрсәтә һәм, димәк, гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен нигезсез чикләүгә китерә.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституциясе кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләрен федераль закон белән генә һәм конституциячел төзелеш нигезләрен, башка затларның әхлаклылыгын, сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, илнең оборонасын һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итү максатларында кирәк булган кадәр генә чикләүне рөхсәт итә (55 статья, 3 өлеш).

Әлеге конституциячел күрсәтмәләргә Кеше хокуклары гомуми декларациясенең 29 статьясындагы 2 пункты туры килә, аның нигезендә һәр кеше үзенең хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашырганда демократик җәмгыятьтә башкаларның хокукларын һәм ирекләрен тиешенчә тануны һәм ихтирам итүне һәм әхлакның, иҗтимагый тәртипнең һәм гомуми яшәешнең гадел таләпләрен канәгатьләндерүне тәэмин итү максатында закон белән билгеләнгән чикләүләргә генә дучар ителергә тиеш. Шундый ук нигезләмәләр Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактның 12 статьясындагы 3 пунктында һәм Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турында халыкара пактның 4 статьясында бар.

Димәк, җирле үзидарә органы акты белән гражданнарга дәрәҗәсе буенча федераль закон белән билгеләнгәннәрдән арттырып җибәрелгән бурычлар һәм чикләүләр йөкләү рөхсәт ителми.

Мондый нәтиҗә Россия Федерациясе Конституция Суды позициясенә туры килә, аның буенча Россия Федерациясе субъекты гражданнар хокукларының федераль закон белән билгеләнгән төп гарантияләре белән беррәттән үз законында әлеге хокукларның конкретлаштырылуына, гамәлгә ашырылуының өстәмә механизмнарын булдыруга юнәлгән өстәмә гарантияләрен региональ үзенчәлекләрне (шартларны) исәпкә алып һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарының федераль законнарга каршы килмәве турындагы һәм кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләрен федераль законнан кала башка формада чикләү рөхсәт ителмәве турындагы конституциячел таләпләрне үтәп билгеләргә хокуклы; һәрхәлдә, шундый җайга салуны гамәлгә ашырып, Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысы теге яки бу конституциячел хокукларның асылын үзгәртә торган процедуралар һәм шартлар кертергә һәм аларның Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә федераль законнар белән беркетелгән федераль гарантияләре дәрәҗәсен төшерергә, шулай ук конституциячел хокуклар һәм ирекләрне ничек тә булса чикләүне кертергә тиеш

түгел, чөнки чикләүләрне — Россия Федерациясе Конституциясе билгеләгән максатларда һәм кысаларда — бары тик федераль закон чыгаручы гына билгели ала (2012 елның 18 июлендәге 19-П номерлы Карар).

Мондый шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды Кагыйдәләрнең 3.7.1 пунктындагы беренче абзацы Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дигән нәтиҗәгә килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставын, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 75 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

3. Макыл җирле үзидарәсе Советының 2005 елның 30 июнендәге 7 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 7 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасын һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 3.7.2 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 24 статьясына (икенче өлеш) туры килми дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 декабрендәге 6-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 3.7.1 пунктындагы беренче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип танырга.

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советына — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге Карарда бәян ителгән шул таләпләргә нигезләнгән хокукый позицияләрен исәпкә алып — Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясендә гамәлдә булган хокукый җайга салуга әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

Тиешле үзгәрешләр кертелгәнче, хокук кулланучылар Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге Карарда бәян ителгән хокукый позицияләренә таянырга тиеш.

6. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

7. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә әлеге Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 79-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы граждан Ф.Ф. Гильфанова и Н.Х. Гильфановой на нарушение их конституционных прав и свобод абзацем четвертым пункта 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан, пунктом 2 Порядка подготовки списков граждан, имеющих право на бесплатное получение земельных участков в соответствии со статьей 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан, утвержденного решением Совета Заинского муниципального района Республики Татарстан от 20 января 2012 года № 154, а также указанным решением в целом по порядку его издания**

22 января
2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы граждан Ф.Ф. Гильфанова и Н.Х. Гильфановой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратились граждане Ф.Ф. Гильфанов и Н.Х. Гильфанова с жалобой на нарушение их конституционных прав и свобод пунктом 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан, устанавливающим право бесплатного получения гражданами, имеющими трех и более детей, постоянно проживающими на территории Республики Татарстан, земельных участков из земель, находящихся в государственной или муниципальной собственности.

От заявителей поступили дополнения к жалобе, в которых они оспаривают конституционность пункта 2 Порядка подготовки списков граждан, имеющих право на бесплатное получение земельных участков в соответствии со статьей 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан, утвержденного решением Совета Заинского муниципального района Республики Татарстан от 20 января 2012 года № 154 (далее также — Порядок), а также указанного решения Совета Заинского муниципального района Республики Татарстан в целом по порядку его издания.

Согласно пункту 2 Порядка в списки граждан включаются граждане:

постоянно проживающие на территории Заинского муниципального района Республики Татарстан, имеющие на дату подачи заявления о бесплатном предоставлении земельного участка многодетной семье трех и более детей, в том числе пасынков, падчериц, а также усыновленных (удочеренных) и подопечных (в отношении которых опека и попечительство осуществляются бессрочно либо до достижения ими совершеннолетия), не достигших восемнадцатилетнего возраста;

утратившие на день вступления в силу Закона Республики Та-

тарстан от 18 ноября 2011 года № 90-ЗРТ «О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан» право на предоставление земельного участка в связи с достижением ребенком (детьми) совершеннолетия (достижения восемнадцатилетнего возраста), но если этот ребенок (дети) не достигли восемнадцатилетнего возраста на 17 июня 2011 года. В этом случае заявление о бесплатном предоставлении земельного участка многодетной семье должно быть подано в течение трех лет со дня вступления в силу Закона Республики Татарстан от 18 ноября 2011 года № 90-ЗРТ «О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан».

Как следует из жалобы, дополнений к ней и приложенных копий документов, в семье заявителей родился третий ребенок, в связи с чем в соответствии с земельным законодательством они получили право на предоставление им земельного участка в собственность бесплатно из земель, находящихся в государственной или муниципальной собственности. Граждане Ф.Ф. Гильфанов и Н.Х. Гильфанова указывают, что они обратились в Исполнительный комитет Заинского муниципального района Республики Татарстан с заявлением о предоставлении в собственность бесплатно земельного участка, однако им в устной форме было отказано в приеме документов, поскольку ими еще не было получено свидетельство о рождении третьего ребенка. По утверждению заявителей, после его получения они повторно обратились в Исполнительный комитет Заинского муниципального района Республики Татарстан, где им вновь было отказано в приеме документов, поскольку на дату их подачи старший ребенок уже достиг восемнадцатилетнего возраста и, соответственно, семья не относилась к категории многодетных.

Впоследствии граждане Ф.Ф. Гильфанов и Н.Х. Гильфанова обратились в суд с иском к Исполнительному комитету Заинского муниципального района Республики Татарстан о возложении обязанности предоставить им земельный участок. Между тем решением Заинского городского суда Республики Татарстан, оставленным без изменения апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан, в удовлетворении исковых требований им было отказано.

Как видно из содержания жалобы и дополнений к ней, заявители усматривают нарушение своих конституционных прав положениями абзаца четвертого пункта 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан, которым установлено, что под гражданами, имеющими трех и более детей, понимается многодетная семья, имеющая в своем составе, в частности, родителей, состоящих в браке между собой или не состоящих в браке, но проживающих совместно, либо одного родителя, а также трех и более детей, не достигших восемнадцатилетнего возраста на дату подачи заявления о предоставлении (передаче) в собственность земельного участка. По мнению граждан Ф.Ф. Гильфанова и Н.Х. Гильфановой, право многодетной семьи на бесплатное полу-

чение земельного участка в собственность носит безусловный характер и реализация указанного права не может зависеть от даты подачи соответствующего заявления в уполномоченный орган, как это установлено обжалуемыми положениями.

Заявители также оспаривают конституционность решения Совета Заинского муниципального района Республики Татарстан от 20 января 2012 года № 154 «Об утверждении Порядка подготовки списков граждан, имеющих право на бесплатное получение земельных участков в соответствии со статьей 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан» по порядку его издания. При этом в качестве органа, принявшего этот нормативный правовой акт, они называют главу Заинского муниципального района Республики Татарстан и полагают, что глава района не имел полномочий на издание данного решения.

На основании изложенного граждане Ф.Ф. Гильфанов и Н.Х. Гильфанова просят Конституционный суд Республики Татарстан признать не соответствующими статьям 4, 38, 41, 46, 54 (часть первая), 55, 58 и 60 Конституции Республики Татарстан пункт 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан, а фактически его абзац четвертый, пункт 2 Порядка подготовки списков граждан, имеющих право на бесплатное получение земельных участков в соответствии со статьей 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан, утвержденного решением Совета Заинского муниципального района Республики Татарстан от 20 января 2012 года № 154, а также указанное решение в целом по порядку его издания. Кроме того, заявители просят Конституционный суд Республики Татарстан отменить правоприменительные решения, вынесенные судами общей юрисдикции по их делу.

2. В соответствии с подпунктом 6 статьи 39.5 Земельного кодекса Российской Федерации земельный участок, находящийся в государственной или муниципальной собственности, предоставляется бесплатно в собственность гражданам, имеющим трех и более детей, в случае и в порядке, которые установлены органами государственной власти субъектов Российской Федерации.

В Республике Татарстан указанная норма нашла свое развитие в Земельном кодексе Республики Татарстан, в котором законодатель, действуя в рамках своих дискреционных полномочий, закрепил случаи и порядок бесплатного предоставления в собственность земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, в том числе конкретный перечень необходимых условий для постановки такой семьи на соответствующий учет. Так, в силу взаимосвязанных положений пункта 3 статьи 32 и абзаца первого пункта 9 статьи 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан граждане, имеющие трех и более детей и заинтересованные в предоставлении земельных участков, должны обратиться в уполномоченный орган местного самоуправления по месту постоянного проживания с заявлением о предоставлении земельного участка. Данное правовое регулирование направлено на реализацию права многодетных семей на получение земельных участков, процедура предоставления которых носит заявительный характер и, соот-

ветственно, требует от граждан совершения определенных действий.

Конституционный суд Республики Татарстан в своем постановлении от 26 декабря 2017 года № 77-П уже указывал, что одним из основных условий при формировании органами местного самоуправления перечня земельных участков выступает потребность в земельных участках, которая определяется исходя из списков граждан, имеющих право на их получение, формируемых в зависимости от даты и времени подачи ими заявления.

Оспариваемое законодательное положение, предусматривая необходимость подачи заявления, наделяет тем самым гражданина свободой действий по реализации (отказу от реализации) этого права, а дата подачи такого заявления имеет определяющее значение как для установления факта недостижения детьми в многодетной семье возраста восемнадцати лет, так и для определения очередности граждан в соответствующих списках.

Тем самым абзац четвертый пункта 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан применительно к поставленному заявителями вопросу, исходя из его места в системе действующего правового регулирования, направлен на обеспечение надлежащего функционирования организационно-правового механизма предоставления рассматриваемой меры социальной поддержки и не ставит под сомнение саму возможность осуществления данной законодательно установленной гарантии.

Что касается предусмотренного оспариваемой нормой требования о необходимости соответствия детей в многодетной семье возрастному критерию, а именно недостижение ими восемнадцатилетнего возраста на дату подачи заявления о предоставлении земельного участка, то Конституционный суд Республики Татарстан считает необходимым отметить, что оно в полной мере согласуется с взаимосвязанными положениями статьи 1 Конвенции о правах ребенка от 20 ноября 1989 года и пункта 1 статьи 54 Семейного кодекса Российской Федерации, из содержания которых следует, что под детьми понимаются лица, не достигшие возраста восемнадцати лет (совершеннолетия).

Таким образом, абзац четвертый пункта 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан не может расцениваться как нарушающий конституционные права заявителей в аспектах, указанных ими в жалобе, и, следовательно, не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» данная жалоба не является допустимой.

Кроме того, граждане Ф.Ф. Гильфанов и Н.Х. Гильфанова, оспаривая в своей жалобе конституционность положений пункта 2 Порядка, не привели мотивированных доводов относительно того, каким образом данными положениями нарушаются их права, что не отвечает требованиям пункта 8 части второй статьи 40 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Рес-

публики Татарстан», в связи с чем жалоба в этой части также не может быть принята к рассмотрению Конституционным судом Республики Татарстан.

Относительно доводов заявителей об утверждении оспариваемого Порядка главой Заинского муниципального района Республики Татарстан и отсутствии у него на это полномочий следует отметить, что в соответствии с пунктом 3 статьи 40 Устава Заинского муниципального района Республики Татарстан, принятого решением Совета Заинского муниципального района Республики Татарстан от 24 июня 2014 года № 385, глава указанного района подписывает и обнародует нормативные правовые акты, принятые Советом Заинского муниципального района Республики Татарстан. При этом как само решение от 20 января 2012 года № 154 «Об утверждении Порядка подготовки списков граждан, имеющих право на бесплатное получение земельных участков в соответствии со статьей 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан», принятое Советом Заинского муниципального района Республики Татарстан, так и утвержденный им Порядок размещены на официальном сайте Заинского муниципального района Республики Татарстан — источнике официального опубликования нормативных правовых актов, принимаемых в данном районе. Тем самым довод заявителей о том, что был нарушен порядок издания рассматриваемого нормативного правового акта, является необоснованным.

Проверка же и оценка правоприменительных решений, вынесенных судами общей юрисдикции по конкретному делу граждан Ф.Ф. Гильфанова и Н.Х. Гильфановой, с точки зрения их законности и обоснованности не входят в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы граждан Ф.Ф. Гильфанова и Н.Х. Гильфановой на нарушение их конституционных прав и свобод абзацем четвертым пункта 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан, пунктом 2 Порядка подготовки списков граждан, имеющих право на бесплатное получение земельных участков в соответствии со статьей 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан, утвержденного решением Совета Заинского муниципального района Республики Татарстан от 20 января 2012 года № 154, а также указанным решением в целом по порядку его издания, поскольку она не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде

Республики Татарстан», в соответствии с которыми жалоба признается допустимой, а разрешение поставленного заявителями вопроса неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданам Ф.Ф. Гильфанову и Н.Х. Гильфановой, в Государственный Совет Республики Татарстан и Совет Заинского муниципального района Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 1-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2012 елның 20 гыйнварындагы 154 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга хокуклары булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенең 2 пункты, шулай ук тулысынча күрсәтелгән карар белән аны бастырып чыгару тәртибе буенча үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданнар Ф.Ф. Гыйльфанов һәм Н.Х. Гыйльфанова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
22 гыйнвар
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданнар Ф.Ф. Гыйльфанов һәм Н.Х. Гыйльфанова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданнар Ф.Ф. Гыйльфанов һәм Н.Х. Гыйльфанова Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы өч һәм аннан күбрәк баласы булган, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче гражданнарның дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукын билгели торган 3 пункты белән үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать иттеләр.

Мөрәҗәгать итүчеләрдән шикаятькә өстәмәләр килде, аларда Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2012 елның 20 гыйнварындагы 154 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга хокуклары булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 2 пунктының, шулай ук Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының күрсәтелгән карарының аны бастырып чыгару тәртибе буенча тулысынча конституциячеллегенә дәгъва белдерелә.

Тәртипнең 2 пункты нигезендә гражданнар исемлекләренә түбәндәгеләр кертелә:

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, күпбалалы гаиләгә җир кишәрлеген түләүсез тапшыру турында гариза бирелгән көнгә унсигез яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк баласы, шул исәптән үги уллары,

үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм опекага алынган (үзләренә карата опека һәм попечительлек чикләнмәгән вакытта яисә алар балигъ яшькә җиткәнче гамәлгә ашырыла торган) балалары булган гражданнар;

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 18 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергән көнгә баласы (балалары) балигъ яшькә җитүгә (унсигез яшькә җитүгә) бәйле рәвештә җир кишәрлеге бирелү хокукын югалткан гражданнар, ләкин әлеге бала (балалар) 2011 елның 17 июненә унсигез яшькә җитмәгән булса. Ул очракта күпбалалы гаиләгә җир кишәрлеген түләүсез тапшыру турында гариза «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 18 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергән көннән соң өч ел эчендә бирелергә тиеш.

Шикаятьтән, аңа өстәмәләрдән һәм кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүчеләр гаиләсендә өченче бала туган, шуңа күрә җир законнары нигезендә алар дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукына ия булалар. Гражданнар Ф.Ф. Гыйльфанов һәм Н.Х. Гыйльфанова күрсәткәнчә, алар Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәннәр, ләкин документлар кабул итүдән аларга телдән баш тартылган, чөнки алар өченче балалары туу турында таныклыкны әле алмаган булганнар. Мөрәҗәгать итүчеләр раславынча, аны алгач, алар Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына яңадан мөрәҗәгать иткәннәр, анда документлар кабул итүдән аларга тагын баш тартылган, чөнки аларны бирү көненә олы балаларына унсигез яшь инде тулган булган һәм, димәк, гаилә күпбалалы категориясенә кермәгән.

Шуннан соң гражданнар Ф.Ф. Гыйльфанов һәм Н.Х. Гыйльфанова Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына аларга җир кишәрлеген бирү бурычын йөкләү турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать иткәннәр. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Зәй шәһәр судының Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган карары белән дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән аларга баш тартылган.

Шикаять һәм аңа өстәмәләр эчтәлегеннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүчеләр Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы нигезләмәләре белән үзләренең конституциячел хокукларының бозылуын күрәләр, аның белән шул билгеләнгән: өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар дигәндә, составында, аерым алганда, язылышкан яисә язылышмаган, әмма бергә яшәүче ата-аналар яки ата-ананың берсе, шулай ук җир кишәрлеген үзләренә милеккә бирү (тапшыру) турында гариза бирелгән көнгә унсигез яше

тулмаган өч һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаилә аңлашыла. Гражданнар Ф.Ф. Гыйльфанов һәм Н.Х. Гыйльфанова фикеренчә, күпбалалы гаиләнең җир кишәрлеген милеккә түләүсез алуга хокукы шартсыз характерга ия һәм күрсәтелгән хокукны гамәлгә ашыру, дәгъвалана торган нигезләмәләр белән билгеләнгәнчә, тиешле гаризаны вәкаләтле органга тапшыру көненә бәйле була алмый.

Мөрәҗәгать итүчеләр шулай ук «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга хокуклары булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2012 елның 20 гыйнварындагы 154 номерлы карарының аны бастырып чыгару тәртибе буенча конституциячеллегенә дәгъва белдерәләр. Шул ук вакытта әлеге норматив хокукый актны кабул иткән орган буларак алар Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгын атыйлар һәм район башлыгының әлеге карарны бастырып чыгарырга вәкаләтләре булмаган дип саныйлар.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар Ф.Ф. Гыйльфанов һәм Н.Х. Гыйльфанова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Конституциясенең 4, 38, 41, 46, 54 (беренче өлеш), 55, 58 һәм 60 статьяларына Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктын, ә фактта аның дүртенче абзацын, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2012 елның 20 гыйнварындагы 154 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга хокуклары булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенең 2 пунктын, шулай ук тулысынча күрсәтелгән карарны аны бастырып чыгару тәртибе буенча туры килми дип тануны сорыйлар. Моннан тыш, мөрәҗәгать итүчеләр Татарстан Республикасы Конституция судыннан аларның эше буенча гомуми юрисдикциядәге судлар тарафыннан чыгарылган хокук куллану карарларын гамәлдән чыгаруны сорыйлар.

2. Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясындагы 6 пунктчасы нигезендә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар милкенә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә түләүсез бирелә.

Татарстан Республикасында күрсәтелгән норма Татарстан Республикасы Җир кодексында үсеш алган, анда, үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә эш итеп, закон чыгаручы өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез бирү очракларын һәм тәртибен, шул исәптән андый гаиләне тиешле исәпкә кую өчен кирәкле шартларның конкрет исемлеген беркеткән. Шулай, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының һәм 32.1 статьясындагы 9 пунктының беренче абзацының үзара бәйләнештәге нигезләмәләре буенча өч һәм аннан күбрәк бала-

сы булган һәм җир кишәрлекләре бирүдә кызыксынучы гражданнар җир кишәрлеге бирү турында гариза белән даими яшәү урыны буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле органына мөрәҗәгать итәргә тиеш. Әлеге хокукый җайга салу күпбалалы гаиләләрнең җир кишәрлекләрен алуга хокукын гамәлгә ашыруга юнәлгән, аларны бирү процедурасы мөрәҗәгать итү характерына ия һәм, димәк, гражданнардан аерым гамәлләр кылуны таләп итә.

Татарстан Республикасы Конституция суды үзенең 2017 елның 26 декабрендәге 77-П номерлы карарында җирле үзидарә органнары җир кишәрлекләре исемлеген булдырганда төп шартларның берсе булып җир кишәрлекләренә ихтыяҗ тора, әлеге ихтыяҗ аларны алырга хокукы булган гражданнарның гариза бирелү көне һәм вакытына карап булдырыла торган исемлекләреннән чыгып билгеләнә дип күрсәткән иде инде.

Гариза бирү кирәклеген күздә тотып, дәгъвалана торган закон нигезләмәсе шуның белән гражданга әлеге хокукны тормышка ашыру (тормышка ашырудан баш тарту) буенча гамәлләр иреге бирә, ә шундый гаризаны бирү көне күпбалалы гаиләдәге балаларга унсигез яшь тулмау фактын ачыклау өчен дә, тиешле исемлекләрдә гражданнарның чиратын билгеләү өчен дә әһәмияткә ия.

Шуның белән Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы, гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы урыныннан чыгып, мөрәҗәгать итүчеләр куйган мәсьәлә буенча карала торган социаль ярдәм чарасын күрсәтүнең оештыру-хокукый механизмының тиешенчә эшләп торуын тәэмин итүгә юнәлгән һәм әлеге законда билгеләнгән гарантияне тормышка ашыру мөмкинлеген шик астына куймый.

Күпбалалы гаиләдә балаларның яшь критериена туры килүе, атап әйткәндә, җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү көненә аларның унсигез яшькә җитмәве кирәклеге турындагы дәгъвалана торган норма белән каралган таләпкә килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды шуны билгеләп үтәргә кирәк дип саный: әлеге таләп 1989 елның 20 ноябрендәге Бала хокуклары турында конвенциянең 1 статьясының һәм Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясындагы 1 пунктының үзара бәйләнештәге нигезләмәләре белән тулысынча яраша, аларның эчтәлегеннән балалар дип унсигез яше тулмаган (балигъ яшькә җитмәгән) затларның саналуы аңлашыла.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы мөрәҗәгать итүчеләрнең конституциячел хокукларын шикаятьтә алар тарафыннан күрсәтелгән аспектларда боза торган буларак карала алмый һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясында-

гы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә әлеге шикаять карала алмый.

Моннан тыш, шикаятьтә Тәртипнең 2 пунктындагы нигезләмәләрнең конституциячеллегенә дәгъва белдереп, гражданнар Ф.Ф. Гыйльфанов һәм Н.Х. Гыйльфанова әлеге нигезләмәләр белән аларның хокуклары ни рәвешле бозылуын аңлата торган дәлилләр китермиләр, бу исә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 40 статьясындагы икенче өлешенең 8 пункты таләпләренә җавап бирми, шуңа күрә шикаять әлеге өлешендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга шулай ук алына алмый.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең дәгъвалана торган Тәртипнең Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслануы һәм моңа аның вәкаләтләре булмавы турындагы дәлилләренә килгәндә, шуны билгеләп үтәргә кирәк: Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 24 июнендәге 385 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 40 статьясындагы 3 пункты нигезендә күрсәтелгән районның башлыгы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы кабул иткән норматив хокукый актларны имзалый һәм халыкка җиткерә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы кабул иткән «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга хокуклары булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибен раслау турында» 2012 елның 20 гыйнварындагы 154 номерлы карар да, аның тарафыннан расланган Тәртип тә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында — әлеге районда кабул ителә торган норматив хокукый актларны рәсми рәвештә бастырып чыгару чыганагында урнаштырылган. Шуның белән мөрәҗәгать итүчеләрнең карала торган норматив хокукый актны бастырып чыгару тәртибе бозылган булуы турындагы дәлиле нигезсез.

Гражданнар Ф.Ф. Гыйльфановның һәм Н.Х. Гыйльфанованың конкрет эше буенча гомуми юрисдикциядәге судлар тарафыннан чыгарылган хокук куллану карарларын законлы һәм нигезле булу-булмау ягыннан тикшерү һәм бәяләү Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2012 елның 20 гыйнварындагы 154 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга хокуклары булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенең 2 пункты, шулай ук тулысынча күрсәтелгән карар белән аны бастырып чыгару тәртибе буенча үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданнар **Ф.Ф.** Гыйльфанов һәм Н.Х. Гыйльфанова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми, ә мөрәҗәгать итүчеләр куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданнар **Ф.Ф.** Гыйльфановка һәм Н.Х. Гыйльфановага, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 1-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

23 марта
2018 года
город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению ходатайства гражданки А.Р. Ефимовой об официальном разъяснении определения Конституционного суда Республики Татарстан от 27 ноября 2017 года № 38-О**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Э.М. Мустафиной, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение обращения гражданки А.Р. Ефимовой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка А.Р. Ефимова с ходатайством об официальном разъяснении определения Конституционного суда Республики Татарстан от 27 ноября 2017 года № 38-О, которым заявительнице было отказано в принятии к рассмотрению жалобы на нарушение ее конституционных прав и свобод:

пунктом 3 статьи 7, статьей 11 и пунктом 5 статьи 13 Закона Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ «О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан»;

абзацем шестым пункта 5.2 Правил и порядка постановки на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки в Республике Татарстан, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 15 апреля 2005 года № 190 (далее — Правила и порядок постановки на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки в Республике Татарстан);

пунктом 7 Порядка определения условий и сроков рассрочки платежей граждан для приобретения жилья по социальной ипотеке, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 366 «О дальнейших мерах по реализации Закона Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ “О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан” и совершенствованию порядка предоставления жилья в рамках республиканской государственной поддержки» (в редакции постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 19 августа 2016 года № 576);

абзацем первым пункта 1 Правил осуществления выплат при рождении, а также при усыновлении (удочерении) каждого ребенка семье, реализующей право на жилище в соответствии с Законом Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ «О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан» и зарегистрированной в качестве нуждающейся в государственной поддержке в улучшении жилищ-

ных условий, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 31 августа 2012 года № 748.

Конституционный суд Республики Татарстан в определении от 27 ноября 2017 года № 38-О пришел к выводу, что обжалуемые заявительницей нормативные положения не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан.

В ходатайстве о разъяснении данного определения Конституционного суда Республики Татарстан, а также в дополнении к нему гражданка А.Р. Ефимова указывает, что правоприменительные органы придают оспариваемым нормам неверное истолкование, в связи с чем просит разъяснить определение Конституционного суда Республики Татарстан от 27 ноября 2017 года № 38-О по следующему вопросу: подлежит ли предоставлению выплата при рождении ребенка в том случае, когда с гражданином заключен договор социальной ипотеки и он, следовательно, реализует право на государственную поддержку в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки в соответствии с Законом Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ «О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан», но при этом не принят на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки.

2. В соответствии со статьей 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» официальное разъяснение решения Конституционного суда Республики Татарстан дается только самим Конституционным судом Республики Татарстан в своем заседании, в частности, по ходатайству лица, имеющего право на обращение в Конституционный суд Республики Татарстан. Как уже отмечал Конституционный суд Республики Татарстан, по смыслу данной нормы в ее взаимосвязи со статьей 68 указанного Закона Республики Татарстан официальное разъяснение не может быть простым воспроизведением решения суда и не должно выходить за пределы произведенной Конституционным судом Республики Татарстан проверки конституционности соответствующего нормативного правового акта (определения от 4 октября 2001 года № 5-О и от 14 декабря 2005 года № 11-О).

Конституционный Суд Российской Федерации также указывал, что ходатайство о даче официального разъяснения не может быть рассмотрено, если представленные в нем вопросы не требуют какого-либо дополнительного истолкования решения по существу или формулирования новых правовых позиций (определения от 20 апреля 2010 года № 593-О-Р, от 24 сентября 2013 года № 1270-О-Р, от 24 декабря 2013 года № 1928-О-Р).

Отказывая в принятии к рассмотрению жалобы заявительницы, Конституционный суд Республики Татарстан отметил, что основополагающим условием реализации гражданами права на получение законодательно предусмотренных мер государственной поддержки в системе социальной ипотеки, в силу обжалуемых нормативных правовых актов, является постановка их на учет нужда-

ющихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки.

Перечень общеобязательных и дополнительных оснований для постановки гражданина на такой учет определен в пункте 5 Правил и порядка постановки на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки в Республике Татарстан, из содержания которого следует, что этот перечень не является закрытым, то есть предусматривает и иные, не определенные в этом пункте основания для принятия его на такой учет с целью оценки уполномоченными органами публичной власти реальной нуждаемости гражданина в предоставлении ему права на приобретение жилья на льготных условиях.

Применительно к вопросу, поставленному заявительницей в ходатайстве, это означает, что процедуре включения гражданина в Реестр специализированной организации (некоммерческой организации «Государственный жилищный фонд при Президенте Республики Татарстан») и подписания с ним договора социальной ипотеки в обязательном порядке предшествует единая для всех процедура постановки граждан на соответствующий учет, являющаяся неотъемлемой частью порядка включения граждан в систему социальной ипотеки. Соответственно только после постановки гражданина на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки и подписания с ним договора социальной ипотеки он считается включенным в данную систему и реализует все предоставляемые в этой системе права, в том числе и право на получение рассматриваемой меры государственной поддержки.

Тем самым содержание и смысл определения Конституционного суда Республики Татарстан от 27 ноября 2017 года № 38-О выражены исчерпывающим образом, полностью основаны на нормах действующего законодательства и какая-либо правовая неопределенность по ним отсутствует. Вследствие этого указанное определение Конституционного суда Республики Татарстан не требует дополнительной детализации или уточнения.

Из ходатайства гражданки А.Р. Ефимовой следует, что ее обращение в Конституционный суд Республики Татарстан обусловлено, по сути, не отсутствием определенности или ясности в правовой позиции, сформулированной в определении от 27 ноября 2017 года № 38-О, а ее несогласием с интерпретацией оспариваемых норм в правоприменительной практике. Между тем Конституционным судом Республики Татарстан не оценивались правомерность действий некоммерческой организации «Государственный жилищный фонд при Президенте Республики Татарстан» при разрешении поставленного заявительницей вопроса, а также законность и обоснованность решений судов общей юрисдикции, поскольку в силу части девятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан решает исключительно вопросы права и при осуществлении конституционного судопроизводства воздерживается от установления и исследования фактических обстоятельств

во всех случаях, когда это входит в компетенцию других судов или иных органов государственной власти Республики Татарстан.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 6, пунктом 3 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, частями первой, второй и шестой статьи 68, статьями 69, 72, 73 и 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению ходатайства гражданки А.Р. Ефимовой об официальном разъяснении определения Конституционного суда Республики Татарстан от 27 ноября 2017 года № 38-О, поскольку для разрешения поставленного заявительницей вопроса официальное разъяснение данного определения не требуется.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данному обращению окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке А.Р. Ефимовой, в Государственный Совет Республики Татарстан, Кабинет Министров Республики Татарстан и некоммерческую организацию «Государственный жилищный фонд при Президенте Республики Татарстан».

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 2-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Татарстан Республикасы Конституция судының 2017 елның 27 ноябрендәге 38-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында гражданка А.Р. Ефимова үтенечнамәсен карауга алудан баш тарту хакында**

2018 ел
23 март
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка А.Р. Ефимова мөрәҗәгатен алдан өйрәнгән судья Э.М. Мостафина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка А.Р. Ефимова Татарстан Республикасы Конституция судының 2017 елның 27 ноябрендәге 38-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында үтенечнамә белән мөрәҗәгать итте, аның белән мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятен карауга алудан баш тартылды:

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 3 пункты, 11 статьясы һәм 13 статьясындагы 5 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләре һәм тәртибенең (алга таба — Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләре һәм тәртибе) 5.2 пунктындагы алтынчы абзацы;

«“Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында” 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 19 августындагы 576 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм вакытларын билгеләү тәртибенең 7 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел-

ның 31 августындагы 748 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукын гамәлгә ашыручы һәм торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә мохтаҗ буларак теркәлгән гаиләгә һәр бала туганда, уллыкка (кызлыкка) алынганда түләүләр гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 1 пунктындагы беренче абзацы.

Татарстан Республикасы Конституция суды 2017 елның 27 ноябрендәге 38-О номерлы билгеләмәсендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмәләрдә аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк дигән нәтиҗәгә килде.

Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге билгеләмәсен аңлату турындагы үтенечнамәдә, шулай ук аңа өстәмәдә гражданка А.Р. Ефимова хокук куллану органнары дәгъвалана торган нормаларга ялгыш аңлатма бирәләр дип күрсәтә, шуңа күрә Татарстан Республикасы Конституция судының 2017 елның 27 ноябрендәге 38-О номерлы билгеләмәсен түбәндәге мәсьәлә буенча аңлатуны сорый: бала туганнан соң бирелә торган түләү граждан белән социаль ипотека шартнамәсе төзелгән һәм, димәк, ул социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә хокукны «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашырган, ләкин шул ук вакытта социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алуга куелмаган очракта бирелергә тиешме, тиеш түгелме.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 77 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карарына рәсми аңлатма, аерым алганда, Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукына ия затның үтенечнамәсе буенча бары тик Татарстан Республикасы Конституция судының үзе тарафыннан үз утырышында гына бирелә. Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләп үткәнчә, рәсми аңлатма, күрсәтелгән Законның 68 статьясы белән үзара бәйләнештә әлеге норманың мәгънәсе буенча, суд карарын гади кабатлау гына була алмый һәм тиешле норматив хокукый актның конституциячеллеген Татарстан Республикасы Конституция суды башкарган тикшерү чикләреннән чыкмаска тиеш (2001 елның 4 октябрендәге 5-О номерлы һәм 2005 елның 14 декабрендәге 11-О номерлы билгеләмәләр).

Россия Федерациясе Конституция Суды рәсми аңлатма бирү турындагы үтенечнамә, әгәр анда бирелгән сораулар карарны асылда ничек тә булса өстәмә аңлатуны яисә яңа хокукый позицияләр формалаштыруны таләп итмәсә, карала алмый дип шулай ук күрсәткән иде (2010 елның 20 апрелендәге 593-О-Р номерлы, 2013 елның 24 сентябрендәге 1270-О-Р номерлы, 2013 елның 24 декабрендәге 1928-О-Р номерлы билгеләмәләр).

Мөрәҗәгать итүченең шикаятен карауга алудан баш тартып, Татарстан Республикасы Конституция суды шуны билгеләп үтте: гражданнарның социаль ипотека системасында исемлеге законда билгеләнгән дәүләт ярдәме чаралары күрсәтелүгә хокукын гамәлгә ашыруның төп нигез шарты булып, дәгъвалана торган норматив хокукый актлар буенча, аларны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алуга кую тора.

Гражданны шундый исәпкә алу өчен гомуммәҗбүри һәм өстәмә нигезләр исемлеге Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләре һәм тәртибенең 5 пунктында билгеләнгән, аның эчтәлегеннән аңлашылганча, әлеге исемлек ябык түгел, ягъни гавами хакимиятнең вәкаләтле органнары тарафыннан гражданның ташламалы шартларда торак алуга хокукны аңа бирүгә чынбарлыкта мохтаҗ булу-булмавын бәяләү максатларында аны шундый исәпкә алу өчен башка, әлеге пункта билгеләнмәгән нигезләр күздә тота.

Мөрәҗәгать итүче үтенечнамәдә куйган мәсьәләгә карата бу шуны аңлата: гражданны Махсуслаштырылган оешма («Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы) реестрына кертү һәм аның белән социаль ипотека шартнамәсен имзалау процедурасына кадәр мәҗбүри рәвештә бөтен кеше өчен дә бердәм булган гражданнарны тиешле исәпкә алу процедурасы үткәрелә, ул гражданнарны социаль ипотека системасына кертү тәртибенең аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Димәк, граждан социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алуга куелгач һәм аның белән социаль ипотека шартнамәсе төзелгәч кенә ул әлеге системага кертелгән булып санала һәм шул системада бирелә торган барлык хокукларны, шул исәптән карала торган дәүләт ярдәме чарасы күрсәтелүгә хокукны гамәлгә ашыра.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция судының 2017 елның 27 ноябрендәге 38-О номерлы билгеләмәсенең эчтәлеге һәм мәгънәсе җитәрлек дәрәҗәдә ачык чагылдырылган, гамәлдәге законнар нормаларына тулысынча таяна һәм алар буенча нинди дә булса хокукый билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция судының күрәтелгән билгеләмәсе өстәмә тәфсилләүне яисә анықлауны таләп итми.

Гражданка А.Р. Ефимова үтенечнамәсеннән аңлашылганча, аның Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгате, асылда, 2017 елның 27 ноябрендәге 38-О номерлы билгеләмәдә булдырылган хокукый позициядә билгелелек яки ачыклык булу-булмауга түгел, ә дәгъвалана торган нормаларның хокук куллану практикасындагы интерпретациясе белән килешмәвенә бәйле. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл иткәндә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы гамәлләренең законга ярашлы булу-булмавы, шулай ук гомуми юрисдикциядәге

судлар карарларының законлы һәм нигезле булу-булмавы Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан бәяләнмәде, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда фактлагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 68 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 77 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судының 2017 елның 27 ноябрендәге 38-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында гражданка А.Р. Ефимова үтенечнамәсен карауга алудан баш тартырга, чөнки мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү өчен әлеге билгеләмәне рәсми аңлату таләп ителми.
2. Бу мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка А.Р. Ефимовага, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 2-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.П. Привалова на нарушение его конституционных прав и свобод абзацем третьим пункта 1 статьи 2 и статьей 5 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»**

6 апреля
2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина В.П. Привалова,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин В.П. Привалов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод абзацем третьим пункта 1 статьи 2 и статьей 5 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан).

В соответствии с оспариваемыми положениями абзаца третьего пункта 1 статьи 2 Закона Республики Татарстан меры государственной адресной социальной поддержки ветеранам труда устанавливаются в порядке, предусмотренном законодательством Республики Татарстан, а обжалуемой статьей 5 Закона Республики Татарстан определен конкретный перечень таких мер и закреплены условия их предоставления.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявитель является ветераном военной службы, ветераном боевых действий, инвалидом, ветераном труда и на основании своего заявления получает меры социальной поддержки как ветеран боевых действий в соответствии с Федеральным законом от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах», поэтому в предоставлении мер социальной поддержки как ветерану труда по Закону Республики Татарстан ему отказывают. Однако гражданин В.П. Привалов считает, что он как ветеран военной службы должен быть приравнен к ветеранам труда и получать соответствующие меры социальной поддержки, установленные как ветеранам военной службы, так и ветеранам труда.

Решением Кировского районного суда города Казани, оставленным без изменения апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан, в удовлетворении исковых требований заявителя к отделу социальной защиты Кировского района города Казани о взыскании убытков, причиненных бездействием специалистов отдела социальной защиты, и компенсации морального вреда было отказано.

В обоснование своей позиции гражданин В.П. Привалов указы-

вает, что согласно статье 23 Федерального закона «О ветеранах» (в редакции, действовавшей до 1 января 2005 года) ветераны военной службы по достижении возраста, дающего право на пенсию по старости, приобретали право на льготы, установленные для ветеранов труда, и до вступления в силу Федерального закона от 22 августа 2004 года № 122-ФЗ «О внесении изменений в законодательные акты Российской Федерации и признании утратившими силу некоторых законодательных актов Российской Федерации в связи с принятием федеральных законов «О внесении изменений и дополнений в Федеральный закон «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» и «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» ветераны труда в соответствии с Федеральным законом «О ветеранах» имели право на транспортные льготы, льготы по оплате услуг за пользование радио и коллективной антенной, а также льготы по оплате жилищно-коммунальных услуг.

Заявитель отмечает, что меры социальной поддержки ветеранов труда, а также граждан, приравненных к ним по состоянию на 31 декабря 2004 года, определяются законами и иными нормативными правовыми актами субъектов Российской Федерации, однако, по его мнению, абзацем третьим пункта 1 статьи 2 Закона Республики Татарстан к категории граждан, которым устанавливаются меры государственной адресной социальной поддержки, отнесены непосредственно ветераны труда без учета лиц, приравненных к ветеранам труда, в частности ветеранов военной службы, а оспариваемой статьей 5 Закона Республики Татарстан меры социальной поддержки также установлены только ветеранам труда.

Тем самым гражданин В.П. Привалов полагает, что в Республике Татарстан на основании обжалуемых положений меры государственной адресной социальной поддержки, установленные ветеранам труда, не предоставляются лицам, приравненным к ветеранам труда, в частности ветеранам военной службы, что нарушает его конституционные права и свободы, и просит Конституционный суд Республики Татарстан признать их не соответствующими статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 54 (часть первая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Федеральным законом от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах» в целях создания условий, обеспечивающих им достойную жизнь, активную деятельность, почет и уважение в обществе, определены категории ветеранов, в том числе ветераны боевых действий, ветераны военной службы и ветераны труда, которым установлены правовые гарантии социальной защиты. Как отметил Конституционный Суд Российской Федерации, согласно статье 23 данного Федерального закона (в редакции, действовавшей до 1 января 2005 года) ветераны военной службы по достижении возраста, дающего право на пенсию по старости, приобретали право на льготы, установленные для ветеранов труда, т.е. были приравнены при предоставлении мер социальной защиты к ветеранам труда. Признание данной статьи в соответствии с пунктом 18 статьи 44

Федерального закона от 22 августа 2004 года № 122-ФЗ утратившей силу не означает, что эта категория ветеранов исключена федеральным законодателем из числа лиц, которым гарантируется предоставление мер социальной поддержки, а решение вопроса об обеспечении их мерами социальной поддержки оставлено на усмотрение субъекта Российской Федерации (Определение от 1 декабря 2005 года № 521-О).

Статья 22 Федерального закона «О ветеранах» (в редакции Федерального закона от 22 августа 2004 года № 122-ФЗ) предусматривает, что меры социальной поддержки ветеранов труда и лиц, приравненных к ним по состоянию на 31 декабря 2004 года, определяются законами и иными нормативными правовыми актами субъектов Российской Федерации, и в соответствии с пунктом 2 статьи 10 указанного Федерального закона они являются расходными обязательствами субъектов Российской Федерации.

Законом Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» с 1 января 2005 года меры социальной поддержки ветеранам труда предоставляются в соответствии с обжалуемой статьей 5 указанного Закона.

Вопросы, связанные с предоставлением мер социальной поддержки ветеранам труда в соответствии с указанным Законом Республики Татарстан, уже были предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан, который отметил, что меры, предусмотренные для вышеуказанной категории граждан, распространяются и на приравненных к ним ветеранов военной службы (постановление от 18 июля 2006 года № 21-П).

Кроме того, рассматривая нормы оспариваемого Закона Республики Татарстан, регламентирующие предоставление мер социальной поддержки для различных категорий ветеранов, Конституционный суд Республики Татарстан установил, что Республика Татарстан обеспечила соблюдение условий и требований, установленных при передаче правового регулирования с федерального уровня на уровень субъекта Российской Федерации, в том числе и требования о введении эффективных правовых механизмов, обеспечивающих не только сохранение, но и возможное повышение уровня социальной защиты ветеранов (постановления от 22 февраля 2007 года № 23-П и от 6 мая 2009 года № 34-П).

Таким образом, обжалуемые нормы сами по себе не могут рассматриваться как нарушающие конституционные права граждан, в том числе и гражданина В.П. Привалова, и, следовательно, не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявителя не является допустимой.

Вместе с тем отсутствие неопределенности в вопросе о распространении мер социальной поддержки, установленных оспариваемым Законом Республики Татарстан для ветеранов труда, на лиц, приравненных к ним, не препятствует республиканскому законодателю в порядке реализации своих дискреционных полномочий

совершенствовать правовое регулирование рассматриваемых норм.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72 и 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.П. Привалова на нарушение его конституционных прав и свобод абзацем третьим пункта 1 статьи 2 и статьей 5 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину В.П. Привалову и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 3-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының өченче абзацы һәм 5 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
6 апрель
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин В.П. Привалов шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин В.П. Привалов «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 2 статьясындагы 1 пунктының өченче абзацы һәм 5 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының өченче абзацының дәгъвалана торган нигезләмәләре буенча хезмәт ветераннарына дәүләт адреслы социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә билгеләнә, ә Татарстан Республикасы Законының дәгъвалана торган 5 статьясы белән шундый чараларның конкрет исемлеге билгеләнгән һәм аларны күрсәтү шартлары беркетелгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — хәрби хезмәт ветераны, сугыш хәрәкәтләре ветераны, инвалид, хезмәт ветераны һәм ул үз гаризасы нигезендә социаль ярдәм күрсәтү чараларын сугыш хәрәкәтләре ветераны буларак «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ала, шуңа күрә аңа хезмәт ветераны буларак социаль ярдәм чараларын Татарстан Республикасы Законы буенча күрсәтүдән баш тарталар. Ләкин гражданин В.П. Привалов хәрби хезмәт ветераны буларак ул хезмәт ветераннарына тиңләштерелергә һәм хәрби хезмәт ветераннарына да, шулай ук хезмәт ветераннарына да билгеләнгән тиешле социаль ярдәм күрсәтү чараларын алырга тиеш дип саный.

Казан шәһәре Киров район судының Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган кара-

ры белән мөрәҗәгать итүченең Казан шәһәре Киров районы социаль яклау бүлегенә социаль яклау бүлеге белгечләренең гамәл кылмаулары белән салынган зыянны түләттерү һәм әхлакый зыянны компенсацияләү турындагы дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган.

Үз позициясен дәлилләп, гражданин В.П. Привалов шуны күрсәтә: «Ветераннар турында» Федераль законның (2005 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган редакциясендә) 23 статьясы буенча хәрби хезмәт ветераннары, картлык буенча пенсия алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч, хезмәт ветераннары өчен билгеләнгән ташламалар алуга хокуклы булганнар һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларын үз көчен югалткан дип тану турында» 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергәнче хезмәт ветераннары «Ветераннар турында» Федераль закон нигезендә транспорт ташламаларына, радио һәм күмәк антеннадан файдалану өчен түләүгә ташламаларга, шулай ук торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташламаларга хокуклы булганнар.

Мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, хезмәт ветераннарына, шулай ук 2004 елның 31 декабренә аларга тиңләштерелгән гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә, ләкин, аның фикеренчә, Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының өченче абзацы белән дәүләт адреслы социаль ярдәм күрсәтү чаралары билгеләнә торган гражданнар категориясенә, хезмәт ветераннарына тиңләштерелгән затларны, аерым алганда, хәрби хезмәт ветераннарын исәпкә алмыйча, турыдан-туры хезмәт ветераннары кертелгән, ә Татарстан Республикасы Законының дәгъвалана торган 5 статьясы белән социаль ярдәм күрсәтү чаралары шулай ук бары тик хезмәт ветераннарына гына билгеләнгән.

Шуның белән гражданин В.П. Привалов Татарстан Республикасында дәгъвалана торган нигезләмәләр буенча хезмәт ветераннарына билгеләнгән дәүләт адреслы социаль ярдәм чаралары хезмәт ветераннарына тиңләштерелгән затларга, аерым алганда, хәрби хезмәт ветераннарына күрсәтелми, бу исә аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза дип саный һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан аларны Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон белән, аларга лаеклы тормыш, актив эшчәнлек, җәмгыятьтә хөрмәт һәм ихтирам тәэмин итә торган шартлар булдыру максатыннан, социаль яклауның хо-

кукый гарантияләре каралган ветераннар категорияләре, шул исәптән сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт ветераннары, хезмәт ветераннары билгеләнгән. Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, әлеге Федераль законның (2005 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган редакциясендә) 23 статьясы буенча хәрби хезмәт ветераннары, картлык буенча пенсия алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч, хезмәт ветераннары өчен билгеләнгән ташламалар алуга хокуклы булганнар, ягъни социаль ярдәм чараларын күрсәткәндә хезмәт ветераннарына тиңләштерелгәннәр. Әлеге статьяны 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 18 пункты нигезендә үз көчен югалткан дип тану федераль закон чыгаручы тарафыннан ветераннарның әлеге категориясе социаль ярдәм чараларын күрсәтү гарантияләнә торган затлар исәбеннән чыгарылган дигәнне аңлатмый, ә аларны социаль ярдәм күрсәтү чаралары белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итү Россия Федерациясе субъекты карамагына калдырылган (2005 елның 1 декабрендәге 521-О номерлы Билгеләмә).

«Ветераннар турында» Федераль законның (2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 22 статьясы хезмәт ветераннарына һәм 2004 елның 31 декабренә аларга тиңләштерелгән затларга социаль ярдәм күрсәтү чаралары Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә дип күздә тота, һәм күрсәтелгән Федераль законның 10 статьясындагы 2 пункты нигезендә алар Россия Федерациясе субъектларының чыгымнар йөкләмәсе булып торалар.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законы белән 2005 елның 1 гыйнварыннан хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чаралары аталган Законның дәгъвалана торган 5 статьясы нигезендә күрсәтелә.

Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы нигезендә хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү белән бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде, ул билгеләгәнчә, югарыда күрсәтелгән гражданнар категориясе өчен каралган чаралар аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт ветераннарына да кагыла (2006 елның 18 июлендәге 21-П номерлы карар).

Моннан тыш, дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының ветераннарның төрле категорияләре өчен социаль ярдәм чараларын күрсәтүне регламентлый торган нормаларын карап, Татарстан Республикасы Конституция суды шуны билгеләде: Татарстан Республикасы хокукый җайга салуны федераль дәрәҗәдән Россия Федерациясе субъекты дәрәҗәсенә тапшырганда билгеләнгән шартларны һәм таләпләрне, шул исәптән ветераннарның социаль яклау дәрәҗәсен саклап кына калмыйча, арттыру ихтималын да тәэмин итүче нәтиҗәле хокукый механизмнар кертү турындагы таләпне дә үтәүне тәэмин итте (2007 елның 22 февралендәге 23-П номерлы һәм 2009 елның 6 маендагы 34-П номерлы карарлар).

Шулай итеп, дәгъвалана торган нормалар үзләреннән-үзе гражданнарның, шул исәптән гражданин В.П. Приваловның да конституциячел хокукларын боза торган булarak карала алмый һәм, димәк, аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Шул ук вакытта дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законы белән хезмәт ветераннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм күрсәтү чараларының аларга тиңләштерелгән затларга кагылуы мәсьәләсендә билгесезлек булмау республика закон чыгаручысына үзенең дискрецион вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибендә карала торган нормаларның хокукый җайга салынуын камилләштерергә комачауламый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72 һәм 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының өченче абзацы һәм 5 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин В.П. Приваловка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 3-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

13 апреля 2018 года город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.П. Привалова на нарушение его конституционных прав и свобод частью второй пункта 2 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Ф.Р. Волковой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина В.П. Привалова,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин В.П. Привалов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод частью второй пункта 2 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан).

Оспариваемым положением установлено, что гражданам, имеющим одновременно право на получение мер социальной поддержки в соответствии со статьями 4—7 Закона Республики Татарстан и федеральными законами, меры социальной поддержки предоставляются по одному из оснований по выбору гражданина, если иное не установлено федеральным законом.

Из жалобы, дополнения к ней и приложенных к ним копий документов следует, что гражданин В.П. Привалов имеет право на получение мер социальной поддержки по нескольким предусмотренным федеральным и республиканским законодательством основаниям в связи с наличием у него статусов ветерана военной службы, ветерана боевых действий, ветерана труда и инвалида. Заявитель получает меры социальной поддержки, предусмотренные Федеральным законом от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах» для ветеранов боевых действий. В связи с этим органы социальной защиты отказывают ему в предоставлении отдельных мер социальной поддержки по категории «ветеран труда», предусмотренных Законом Республики Татарстан.

Гражданин В.П. Привалов обратился в суд с иском к отделу социальной защиты Кировского района города Казани о взыскании убытков в связи с непредоставлением льгот как ветерану труда и компенсации морального вреда. Решением Кировского районного суда города Казани, оставленным без изменения апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан, в удовлетворении исковых требований гражданину В.П. Привалову отказано.

Заявитель полагает, что законодательство предоставляет ему

право выбора мер социальной поддержки по одному из оснований и он имеет возможность дополнить одни формы социальной поддержки другими формами, предусмотренными разными основаниями. По мнению гражданина В.П. Привалова, меры социальной поддержки ветеранов боевых действий и ветеранов труда отличаются по форме, следовательно, он, являясь ветераном труда, имеет право на получение некоторых мер социальной поддержки, предусмотренных пунктом 1 статьи 5 Закона Республики Татарстан: бесплатное зубопротезирование, субсидия в размере 50 процентов расходов на оплату коммунальных услуг, субсидия в размере 50 процентов затрат по плате за абонентскую линию сети фиксированной телефонной связи.

Федеральный закон от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах», как указывает гражданин В.П. Привалов, в пункте 3 статьи 13 прямо устанавливает, что при наличии у ветерана права на получение одной и той же формы социальной поддержки по нескольким основаниям, социальная поддержка предоставляется по одному основанию по выбору ветерана, за исключением случаев, предусмотренных законодательством. Оспариваемая же норма республиканского закона, как считает заявитель, сужает установленное федеральным законом положение, закрепляя принцип получения фактически любых мер социальной поддержки по одному из оснований по выбору гражданина вне зависимости от различия их форм. Тем самым ограничивается его право на выбор и получение различных по форме мер социальной поддержки.

В связи с этим гражданин В.П. Привалов просит Конституционный суд Республики Татарстан признать часть вторую пункта 2 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» не соответствующей статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 54 (часть первая), 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Специальным законом, определяющим гарантии социальной защиты ветеранов в Российской Федерации, является Федеральный закон от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах» (далее также — Федеральный закон «О ветеранах»), в статье 1 которого установлены категории ветеранов, включая ветеранов боевых действий, ветеранов военной службы, ветеранов труда. В зависимости от основания предоставления мер социальной поддержки, то есть принадлежности к той или иной категории ветеранов, перечень этих мер поддержки различается.

С 1 января 2005 года меры социальной поддержки ветеранов труда в соответствии со статьей 22 Федерального закона «О ветеранах» (в редакции Федерального закона от 22 августа 2004 года № 122-ФЗ) определяются законами и иными нормативными правовыми актами субъектов Российской Федерации. Одновременно с этим в пункте 3 статьи 13 этого же Федерального закона установлено правило, согласно которому при наличии у ветерана права на получение одной и той же формы социальной поддержки по нескольким основаниям социальная поддержка предоставляется

по одному основанию по выбору ветерана, за исключением случаев, предусмотренных законодательством.

Конституционный Суд Российской Федерации уже неоднократно указывал в своих решениях, что такое правовое регулирование, при котором лицам, имеющим одновременно право на социальную поддержку по нескольким предусмотренным законодательством основаниям, социальная поддержка предоставляется по одному из оснований по выбору получателя (за исключением случаев, предусмотренных законодательством), закрепляющее право выбрать наиболее выгодное основание пользования мерами социальной поддержки, не может расцениваться как ущемляющее права граждан (определения от 22 марта 2011 года № 443-О-О; от 21 декабря 2011 года № 1693-О-О; от 29 сентября 2015 года № 1931-О; от 26 апреля 2016 года № 899-О). Правоприменительная практика Верховного Суда Российской Федерации также исходит из того, что Федеральный закон «О ветеранах» не содержит механизма суммирования мер социальной поддержки по разным основаниям и не дает возможности получения одним и тем же лицом мер социальной поддержки, установленных для различных категорий граждан (определение от 17 июля 2013 года № 9-АПГ13-7).

Реализуя предоставленные субъектам Российской Федерации полномочия, республиканский законодатель в Законе Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» установил конкретные по объему и форме меры социальной поддержки для отдельных категорий граждан, в том числе для ветеранов труда. При этом в Законе Республики Татарстан закреплено правило о том, что гражданам, имеющим одновременно право на получение мер социальной поддержки в соответствии со статьями 4—7 данного Закона и федеральными законами, меры социальной поддержки предоставляются по одному из оснований по выбору гражданина, если иное не установлено федеральным законом (часть вторая пункта 2 статьи 9).

Аналогичное правовое регулирование уже было предметом рассмотрения Конституционного Суда Российской Федерации в Определении от 25 февраля 2016 года № 314-О. При этом Конституционный Суд Российской Федерации указал, что норма части 2 статьи 8 Закона Хабаровского края «О мерах социальной поддержки граждан пожилого возраста, инвалидов, ветеранов труда, лиц, проработавших в тылу в период Великой Отечественной войны, семей, имеющих детей, и иных категорий граждан» (в редакции Закона Хабаровского края от 20 декабря 2006 года № 86), согласно которой гражданину, одновременно имеющему право на меры социальной поддержки по данному закону и иным нормативным правовым актам независимо от оснований, по которым они устанавливаются, предоставляются меры социальной поддержки либо по данному закону, либо по иным нормативным правовым актам по выбору гражданина, по существу, воспроизводит положение пункта 3 статьи 13 Федерального закона «О ветеранах».

Таким образом, оспариваемая заявителем норма, закрепляя право выбора более выгодного основания пользования мерами

социальной поддержки отдельных категорий граждан, перечень которых определен в Законе Республики Татарстан, основана на нормах федерального законодательства, не нарушает конституционные принципы равенства и справедливости, не ограничивает права граждан, в том числе гражданина В.П. Привалова, на получение мер социальной поддержки и, следовательно, не содержит неопределенности в вопросе ее соответствия Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявителя не является допустимой.

Гражданин В.П. Привалов, оспаривая конституционность обжалуемого нормативного положения, фактически ставит перед Конституционным судом Республики Татарстан вопрос о необходимости совершенствования существующего нормативно-правового регулирования. Между тем разрешение поставленного вопроса в силу статьи 109 Конституции Республики Татарстан и статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

На основании изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.П. Привалова на нарушение его конституционных прав и свобод частью второй пункта 2 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленного заявителем вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.
2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.
3. Копию настоящего Определения направить гражданину В.П. Привалову и в Государственный Совет Республики Татарстан.
4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 4-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 пунктының икенче өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
13 апрель
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин В.П. Привалов шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин В.П. Привалов «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 9 статьясындагы 2 пунктының икенче өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган нигезләмә белән шул билгеләнгән: бер үк вакытта Татарстан Республикасы Законының 4—7 статьялары һәм федераль законнар нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган гражданнарга, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәсә, нигезләрнең берсе буенча гражданнар сайлаган социаль ярдәм чаралары күрсәтелә.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән һәм шуларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин В.П. Привалов, хәрби хезмәт ветераны, сугыш хәрәкәтләре ветераны, хезмәт ветераны һәм инвалид статуслары булу сәбәпле, социаль ярдәм күрсәтү чараларын федераль һәм республика законнары белән каралган берничә нигез буенча алырга хокуклы. Мөрәҗәгать итүче «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон белән сугыш хәрәкәтләре ветераннары өчен каралган социаль ярдәм күрсәтү чараларын ала. Шуңа бәйле рәвештә социаль яклау органнары Татарстан Республикасы Законы белән «хезмәт ветераны» категориясе буенча каралган аерым социаль ярдәм чараларын күрсәтүдән аңа баш тарталар.

Гражданин В.П. Привалов Казан шәһәре Киров районы социаль яклау бүлегенә хезмәт ветераны буларак ташламалар бирелмәү сәбәпле салынган зыянны түләттерү һәм әхлакый зыянны компенсацияләү турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать иткән. Казан шәһәре Киров район судының Татарстан Республи-

касы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган карары белән гражданин В.П. Приваловка дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган.

Мөрәҗәгать итүче законнар аңа социаль ярдәм күрсәтү чараларын нигезләрнең берсе буенча сайлау хокукын бирәләр һәм аның социаль ярдәм күрсәтүнең аерым формаларын төрле нигезләр белән каралган башка формалар белән тулыландыру мөмкинлеге бар дип саный. Гражданин В.П. Привалов фикеренчә, сугыш хәрәкәтләре ветераннарына һәм хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтү чаралары форма буенча аерыла, димәк, ул хезмәт ветераны буларак Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 пункты белән каралган кайбер социаль ярдәм күрсәтү чараларын алуга хокуклы: түләүсез теш протезлау, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия, чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия.

«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон, гражданин В.П. Привалов күрсәткәнчә, 13 статьясының 3 пунктында турыдан-туры шуны билгели: ветеранның берничә нигез буенча бер үк формадагы социаль ярдәм алырга хокукы булганда, социаль ярдәм, законнарда каралган очраклардан тыш, ветеранның сайлавы буенча бер нигездә күрсәтелә. Республика законының дәгъвалана торган нормасы исә, мөрәҗәгать итүче санаганча, граждан сайлавы буенча нигезләрнең берсе буенча фактта теләсә кайсы социаль ярдәм күрсәтү чараларын аларның формасы аерылуга бәйсез рәвештә алу принцибын беркетеп, федераль закон белән билгеләнгән нигезләмәне тарайта. Шуның белән аның формасы буенча төрле булган социаль ярдәм күрсәтү чараларын сайлауга һәм алуга хокукы чикләнә.

Шуңа бәйле рәвештә гражданин В.П. Привалов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 пунктының икенче өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясендә ветераннарны социаль яклау гарантияләрен билгели торган махсус закон булып «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба шулай ук — «Ветераннар турында» Федераль закон) тора, аның 1 статьясында сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, хәрби хезмәт ветераннарын, хезмәт ветераннарын кертеп, ветераннар категорияләре билгеләнгән. Социаль ярдәм чаралары күрсәтелү нигезенә, ягъни ветераннарның теге яки бу категориясендә булуга карап, әлеге ярдәм чараларының исемлеге аерыла.

2005 елның 1 гыйнварыннан «Ветераннар турында» Федераль законның (2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 22 статьясы нигезендә хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтү чаралары Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә. Шуның белән бергә әлеге Федераль законның 13 статьясындагы 3 пунктында шундый кагыйдә билгеләнгән: ветеранның берничә нигез буенча бер үк формадагы социаль ярдәм алырга хокукы булганда, социаль ярдәм, законнарда каралган очраклардан тыш, ветеранның сайлавы буенча бер нигездә күрсәтелә.

Россия Федерациясе Конституция Суды үз карарларында берничә тапкыр шуны күрсәтте: законнарда каралган берничә нигез буенча социаль ярдәмгә берьюлы хокуклы булган затларга социаль ярдәм алучының сайлавы буенча нигезләрнең берсе буенча күрсәтелә торган (законнарда каралган очраклардан тыш), социаль ярдәм күрсәтү чараларыннан файдалануның иң уңай нигезен сайлап алу хокукын беркетә торган шундый хокукый җайга салу гражданнарның хокукларын чикли торган буларак бәяләнә алмый (2011 елның 22 мартындагы 443-О-О номерлы; 2011 елның 21 декабрендәге 1693-О-О номерлы; 2015 елның 29 сентябрендәге 1931-О номерлы; 2016 елның 26 апрелендәге 899-О номерлы билгеләмәләр). Россия Федерациясе Югары Судының хокук куллану практикасы шулай ук шуңа таяна: «Ветераннар турында» Федераль законда социаль ярдәм күрсәтү чараларын төрле нигезләр буенча кушу механизмы юк, һәм ул гражданнарның төрле категорияләре өчен билгеләнгән социаль ярдәм күрсәтү чараларын бер үк зат тарафыннан алу мөмкинлеген бирми (2013 елның 17 июлендәге 9-АПГ13-7 номерлы билгеләмә).

Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законында гражданнарның аерым категорияләре өчен, шул исәптән хезмәт ветераннары өчен күләме һәм формасы буенча конкрет социаль ярдәм күрсәтү чараларын билгеләгән. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Законында шундый кагыйдә беркетелгән: бер үк вакытта әлеге Законның 4—7 статьялары һәм федераль законнар нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган гражданнарга, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәсә, нигезләрнең берсе буенча гражданнар сайлаган социаль ярдәм чаралары күрсәтелә (9 статьяның 2 пунктындагы икенче өлеше).

Тиңдәш хокукый җайга салу 2016 елның 25 февралендәге 314-О номерлы Билгеләмәдә Россия Федерациясе Конституция Судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. Анда Россия Федерациясе Конституция Суды шуны күрсәтте: «Олы яшьтәге гражданнарга, инвалидларга, хезмәт ветераннарына, Бөек Ватан сугышы чорында тылда эшләгән затларга, балалы гаиләләргә һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» Хабаровск крае Законының (2006 елның 20

декабрендәге 86 номерлы Хабаровск крае Законы редакциясендә) 8 статьясындагы 2 өлеше нормасы, аның нигезендә берьюлы әлеге закон һәм башка норматив хокукый актлар буенча социаль ярдәм күрсәтү чараларына, алар билгеләнә торган нигезләргә бәйсез рәвештә, хокукы булган гражданга социаль ярдәм чаралары граждан сайлавы буенча я әлеге закон, я башка норматив хокукый актлар буенча күрсәтелә, асылда, «Ветераннар турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3 пункты нигезләмәсен кабатлый.

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норма, исемлеге Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чараларыннан файдалануның уңайрак нигезен сайлап алу хокукын беркетеп, федераль законнар нормаларына таянган, тигезлек һәм гаделлек конституциячел принципларын бозмый, гражданнарның, шул исәптән гражданин В.П. Приваловның социаль ярдәм күрсәтү чараларын алуга хокукын чикләми һәм, димәк, норманың Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Карала торган норматив нигезләмәнең конституциячеллегенә дәгъва белдереп, гражданин В.П. Привалов асылда Татарстан Республикасы Конституция суды алдына гамәлдәге норматив-хокукый җайга салуны камилләштерү кирәклеге турында мәсьәлә куя. Шул ук вакытта куелган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 пунктының икенче өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять билгеләнгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин В.П. Приваловка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 4-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.П. Привалова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 2 статьи 3 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»**

20 июня
2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Ф.Р. Волковой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина В.П. Привалова,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин В.П. Привалов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 2 статьи 3 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан).

В соответствии с пунктом 2 статьи 3 Закона Республики Татарстан органы местного самоуправления вправе устанавливать дополнительные меры социальной поддержки указанным в статье 2 названного Закона категориям граждан за счет средств местных бюджетов.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что заявитель получает меры социальной поддержки как ветеран боевых действий. Считая предоставляемый ему объем мер социальной поддержки недостаточным, он обращался в органы социальной защиты Республики Татарстан и в суд, но его обращения, как отмечает гражданин В.П. Привалов, не привели к положительному результату.

Как указал заявитель, в соответствии с пунктом 3 статьи 10 Федерального закона от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах» (далее также — Федеральный закон «О ветеранах») субъекты Российской Федерации в дополнение к мерам социальной поддержки, установленным статьями 14—19 и 21 названного Федерального закона, могут устанавливать иные меры социальной поддержки. Однако, как отмечает гражданин В.П. Привалов, Законом Республики Татарстан такие дополнительные меры не предусмотрены. При этом республиканским законодателем, по его мнению, принята дискриминационная норма, предоставляющая органам местного самоуправления право устанавливать за счет средств местных бюджетов дополнительные меры социальной поддержки только указанным в статье 2 Закона Республики Татарстан категориям граждан. Между тем этим гражданам меры социальной поддержки предоставляются в порядке, предусмотренном законодательством

Республики Татарстан. В связи с этим, как указывает гражданин В.П. Привалов, органы местного самоуправления города Казани не предусмотрели дополнительные меры социальной поддержки федеральных льготников и они оказались в неравном положении с республиканскими льготниками. Такое правовое регулирование, по мнению заявителя, нарушает его конституционные права и свободы.

На основании изложенного гражданин В.П. Привалов просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 2 статьи 3 Закона Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» не соответствующим статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 54 (часть первая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Правовые гарантии социальной защиты ветеранов в Российской Федерации предусмотрены Федеральным законом «О ветеранах». В дополнение к мерам социальной поддержки, установленным данным Федеральным законом, субъекты Российской Федерации могут устанавливать иные меры социальной поддержки законами субъектов Российской Федерации и принимаемыми в соответствии с ними нормативными правовыми актами; такие меры социальной поддержки являются расходными обязательствами субъектов Российской Федерации (пункт 3 статьи 10).

Таким образом, условия социальной поддержки ветеранов определяются органами государственной власти субъекта Российской Федерации самостоятельно с учетом возможностей его бюджета. В целях реализации предоставленных полномочий в Республике Татарстан принят Закон Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», которым определены категории граждан и условия предоставления им адресной социальной поддержки.

Оспариваемой нормой Закона Республики Татарстан органам местного самоуправления предоставлено право устанавливать дополнительные меры социальной поддержки указанным в статье 2 этого Закона категориям граждан за счет средств местных бюджетов. Такой подход согласуется с Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации». Согласно абзацу второму части 5 статьи 20 названного Федерального закона органы местного самоуправления вправе устанавливать за счет средств бюджета муниципального образования (за исключением финансовых средств, передаваемых местному бюджету на осуществление целевых расходов) дополнительные меры социальной поддержки и социальной помощи для отдельных категорий граждан вне зависимости от наличия в федеральных законах положений, устанавливающих указанное право. Абзацем третьим части 5 статьи 20 данного Федерального закона прямо предусмотрено, что финансирование полномочий, предусмотренных указанной частью, не является обязанностью муниципального образования, осуществляется при наличии возможности и не является основа-

нием для выделения дополнительных средств из других бюджетов бюджетной системы Российской Федерации.

Таким образом, установление дополнительных мер социальной поддержки для отдельных категорий граждан по отношению к мерам социальной поддержки, предусмотренным федеральным законодательством и законодательством субъектов Российской Федерации, относится к компетенции органов местного самоуправления. При этом ни федеральное, ни региональное законодательство не предопределяет конкретное содержание публично-правовых обязательств органов местного самоуправления по определению таких дополнительных льгот. Органы местного самоуправления при осуществлении правового регулирования в указанной сфере самостоятельно определяют категории граждан, которым предоставляются меры социальной поддержки, перечень таких мер, условия их предоставления, поскольку обеспечение этих мер является их расходными обязательствами.

Как неоднократно указывал Конституционный Суд Российской Федерации в своих решениях, имеющих общеобязательное значение, Конституция Российской Федерации, относя социальную защиту, включая социальное обеспечение, к совместному ведению Российской Федерации и ее субъектов (статья 72, пункт «ж» части 1), не устанавливает конкретные способы и объем такой защиты, предоставляемой тем или иным категориям граждан,— решение этих вопросов является прерогативой законодателя, который, реализуя при осуществлении правового регулирования конституционные гарантии в социальной сфере, располагает достаточно широкой свободой усмотрения при определении мер социальной защиты, выборе критериев их дифференциации, регламентации условий их предоставления; он вправе также избирать и изменять формы (способы) их предоставления (постановления от 9 июля 2009 года № 12-П, от 10 ноября 2009 года № 17-П); конституционный принцип равенства не препятствует закреплению неодинакового объема мер социальной защиты для лиц, относящихся к различным категориям (Определение от 9 июня 2015 года № 1230-О).

Оспаривая конституционность обжалуемого нормативного положения, заявитель фактически ставит перед Конституционным судом Республики Татарстан вопрос о необходимости совершенствования существующего нормативного правового регулирования. Между тем разрешение поставленного вопроса в силу статьи 109 Конституции Республики Татарстан и статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не относится к полномочиям Конституционного суда Республики Татарстан.

Таким образом, положение пункта 2 статьи 3 Закона Республики Татарстан, предусматривающее право органов местного самоуправления устанавливать дополнительные меры социальной поддержки указанным в статье 2 данного Закона категориям граждан за счет средств местных бюджетов, основано на нормах федерального законодательства, не нарушает конституционные принципы равенства и справедливости и не ограничивает права

граждан, в том числе гражданина В.П. Привалова, на получение мер социальной поддержки и, следовательно, не содержит неопределенности в вопросе соответствия его Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявителя не является допустимой.

На основании изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.П. Привалова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 2 статьи 3 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленного заявителем вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину В.П. Привалову и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 7-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
20 июнь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин В.П. Привалов шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин В.П. Привалов «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 3 статьясындагы 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 пункты нигезендә җирле үзидарә органнары гражданнарның аталган Законның 2 статьясында күрсәтелгән категорияләренә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын билгеләргә хокуклы.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче социаль ярдәм күрсәтү чараларын сугыш хәрәкәтләре ветераны буларак ала. Аңа күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары күләмен җитәрлек түгел дип санап, ул Татарстан Республикасының социаль яклау органнарына һәм судка мөрәҗәгать иткән, ләкин мөрәҗәгатьләре, гражданин В.П. Привалов билгеләгәнчә, уңай нәтиҗәгә китермәгән.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба шулай ук — «Ветераннар турында» Федераль закон) 10 статьясындагы 3 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектлары аталган Федераль законның 14—19 һәм 21 статьялары белән билгеләнгән социаль ярдәм күрсәтү чараларына өстәмә рәвештә башка социаль ярдәм күрсәтү чараларын билгели ала. Ләкин, гражданин В.П. Привалов билгеләгәнчә, Татарстан Республикасы Законы белән андый өстәмә чаралар каралмаган. Монда республика закон чыгаручысы тарафыннан, аның фикеренчә, җирле үзидарә органнарына гражданнарның Татарстан Республикасы Законының 2 статьясында күрсәтелгән

категорияләренә генә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын билгеләү хокукын бирә торган дискриминацияләүче норма кабул ителгән. Шул ук вакытта әлеге гражданнарга социаль ярдәм чаралары Татарстан Республикасы законнары белән каралган тәртиптә күрсәтелә. Шуңа бәйле рәвештә, гражданин В.П. Привалов күрсәткәнчә, Казан шәһәренең җирле үзидарә органнары федераль ташламалардан файдаланучыларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын күздә тотмаганнар һәм алар республика ташламаларыннан файдаланучылар белән тигез булмаган хәлдә калалар. Шундый хокукый җайга салу, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин В.П. Привалов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясендә ветераннарны социаль яклауның хокукый гарантияләре «Ветераннар турында» Федераль закон белән каралган. Әлеге Федераль закон белән билгеләнгән социаль ярдәм күрсәтү чараларына өстәмә буларак, Россия Федерациясе субъектлары Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актлар белән социаль ярдәм күрсәтүнең башка чараларын билгели ала; шундый социаль ярдәм күрсәтү чаралары Россия Федерациясе субъектларының чыгымнар йөкләмәсе булып тора (10 статьяның 3 пункты).

Шулай итеп, ветераннарга социаль ярдәм күрсәтү шартлары Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан аның бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, мөстәкыйль билгеләнә. Татарстан Республикасында бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, аның белән гражданнар категорияләре һәм аларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү шартлары билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Законының дәгъвалана торган нормасы белән җирле үзидарә органнарына гражданнарның әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән категорияләренә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын билгеләү хокукы бирелгән. Мондый алым «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән яраша. Аталган Федераль законның 20 статьясындагы 5 өлешенең икенче абзацы нигезендә җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән (җирле бюджетка максатчан чыгымнарга тоту өчен тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль

булышуның өстәмә чараларын билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел. Әлеге Федераль законның 20 статьясындагы 5 өлешенең өченче абзацы белән күрсәтелгән өлештә каралган вәкаләтләрне финанслау муниципаль берәмлекнең бурычына керми, ул мөмкинлек булганда гына гамәлгә ашырыла һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан өстәмә чаралар бүлеп бирү өчен нигез була алмый дип турыдан-туры каралган.

Шулай итеп, гражданнарның аерым категорияләре өчен федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән каралган социаль ярдәм күрсәтү чаралары мөнәсәбәтендә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын билгеләү җирле үзидарә органнары компетенциясенә керә. Шул ук вакытта федераль законнар да, региональ законнар да җирле үзидарә органнарының шундый өстәмә ташламаларны билгеләү буенча гавами-хокукый бурычларының конкрет эчтәлеген алдан билгеләп куймый. Җирле үзидарә органнары күрсәтелгән өлкәдә хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган гражданнар категорияләрен, шундый чаралар исемлеген, аларны күрсәтү шартларын мөстәкыйль билгелиләр, чөнки әлеге чараларны тәэмин итү аларның чыгымнар йөкләмәсе булып тора.

Россия Федерациясе Конституция Суды үзенең гомуммәҗбүри әһәмияткә ия карарларында берничә тапкыр күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмен билгеләми — әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул, хокукый җайга салуны башкарганда социаль өлкәдәге конституциячел гарантияләрне гамәлгә ашырып, социаль яклау чараларын билгеләгәндә, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлаганда, аларның күрсәтелү шартларын регламентлаштырганда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 9 июлендәге 12-П номерлы, 2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы карарлар); тигезлек конституциячел принцибы төрле категориядәге затлар өчен социаль яклау чараларын тигез булмаган күләмдә беркетүгә каршы төшми (2015 елның 9 июнендәге 1230-О номерлы Билгеләмә).

Карала торган норматив нигезләмәнең конституциячеллегенә дәгъва белдереп, мөрәҗәгать итүче асылда Татарстан Республикасы Конституция суды алдына гамәлдәге норматив хокукый җайга салуны камилләштерү кирәклеге турында мәсьәлә куя. Шул ук вакытта куелган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды вәкаләтләренә керми.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 пунктының җирле үзидарә органнарының гражданнарның әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән категорияләренә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын билгеләү хокукын күздә тота торган нигезләмәсе федераль законнар нормаларына нигезләнгән, тигезлек һәм гаделлек конституциячел принципларын бозмый, гражданнарның, шул исәптән гражданин В.П. Приваловның социаль ярдәм күрсәтү чараларын алуга хокукын чикләми һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять билгеләнгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин В.П. Приваловка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 7-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.П. Привалова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 1 и статьей 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»**

20 июня
2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина В.П. Привалова,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин В.П. Привалов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 1 и статьей 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан».

Согласно пункту 1 статьи 1 оспариваемого Закона Республики Татарстан его действие распространяется на граждан Российской Федерации, проживающих на территории Республики Татарстан, относящихся к категориям, указанным в статье 2 данного Закона.

Статья 2 обжалуемого Закона Республики Татарстан устанавливает категории граждан, которым предоставляются меры адресной социальной поддержки в порядке, предусмотренном законодательством Республики Татарстан.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что гражданин В.П. Привалов является получателем мер социальной поддержки, предусмотренных для ветеранов боевых действий. Считая недостаточным объем социальной поддержки данной категории граждан, заявитель обращался в Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан и в суд общей юрисдикции. Однако, как он отмечает, его обращения не привели к положительному результату.

Заявитель указывает, что в соответствии с пунктом 3 статьи 10 Федерального закона от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах» в дополнение к мерам социальной поддержки, установленным статьями 14—19 и 21 данного Федерального закона, субъекты Российской Федерации могут устанавливать иные меры социальной поддержки законами субъектов Российской Федерации и принимаемыми в соответствии с ними нормативными правовыми актами.

Между тем положениями рассматриваемого Закона Республики Татарстан такие дополнительные меры социальной поддержки не установлены, чем, по мнению гражданина В.П. Привалова, нарушаются его конституционные права. Так, заявитель указывает, что другие субъекты Российской Федерации установили в своем законодательстве соответствующие дополнительные меры социаль-

ной поддержки в объеме, полностью отвечающем требованиям социальной справедливости. В то же время, как он отмечает, заданные Конституцией Республики Татарстан высокие социальные стандарты не нашли отражения в законодательстве республики. Тем самым, по его мнению, предусмотренное республиканским законодателем регулирование не противоречит федеральному законодательству, но противоречит Конституции Республики Татарстан, поскольку в ней содержится значительный блок социальных прав и она закрепляет более высокий уровень социальных гарантий по сравнению с другими субъектами Российской Федерации.

На основании изложенного гражданин В.П. Привалов просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 1 статьи 1 и статью 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» не соответствующими статьям 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 54 (часть первая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Федеральным законом от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» (в редакции Федерального закона от 21 декабря 2013 года № 371-ФЗ) предусмотрено, что органы государственной власти субъекта Российской Федерации вправе устанавливать за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации (за исключением финансовых средств, передаваемых из федерального бюджета бюджету субъекта Российской Федерации на осуществление целевых расходов) дополнительные меры социальной поддержки и социальной помощи для отдельных категорий граждан, в том числе исходя из установленных законами и иными нормативными правовыми актами субъекта Российской Федерации критериев нуждаемости, вне зависимости от наличия в федеральных законах положений, устанавливающих указанное право. Финансирование полномочий, предусмотренное данной статьей, не является обязанностью субъекта Российской Федерации, осуществляется при наличии возможности, а также не является основанием для выделения дополнительных средств из федерального бюджета (части третья и четвертая статьи 26.3-1).

Реализуя предоставленные субъектам Российской Федерации полномочия, республиканский законодатель в Законе Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» определил категории граждан, которым предоставляются меры адресной социальной поддержки в Республике Татарстан, а также конкретные объемы и формы их предоставления.

Конституционный суд Республики Татарстан уже неоднократно указывал, что установленное оспариваемым Законом Республики Татарстан правовое регулирование носит целевой характер, назначением которого является поддержка материального благополучия отдельных категорий граждан, осуществляемая в полном объеме за счет средств бюджета Республики Татарстан, и представляет

собой дополнительную меру социальной поддержки отдельных категорий граждан, установление которой является правом, а не обязанностью Республики Татарстан. Это означает, что основания и условия ее предоставления определяются республикой самостоятельно с учетом имеющихся на данном этапе социально-экономического развития финансовых и иных материальных возможностей (определения от 8 июля 2016 года № 12-О и от 12 июля 2017 года № 32-О).

Такой подход согласуется с правовой позицией Конституционного Суда Российской Федерации, который отмечал, что Конституция Российской Федерации, относя социальную защиту, включая социальное обеспечение, к совместному ведению Российской Федерации и ее субъектов (статья 72, пункт «ж» части 1), не устанавливает конкретные способы и объемы такой защиты, предоставляемой тем или иным категориям граждан. Решение этих вопросов является прерогативой законодателя, который при определении гарантий реализации прав, закрепленных в Конституции Российской Федерации, располагает достаточно широкой свободой усмотрения в выборе мер социальной защиты, критериев их дифференциации, регламентации условий и порядка предоставления; он вправе также избирать и изменять формы (способы) их предоставления (Постановление от 10 ноября 2009 года № 17-П; Определение от 9 ноября 2010 года № 1439-О-О).

Тем самым оспариваемые нормы сами по себе не могут рассматриваться как нарушающие конституционные права граждан, в том числе и гражданина В.П. Привалова, и, следовательно, не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявителя не является допустимой. Разрешение же поставленного им вопроса об изменении порядка предоставления мер социальной поддержки отдельным категориям граждан, в том числе расширение объема их предоставления, предполагает внесение изменений в действующее законодательство, что входит в компетенцию республиканского законодателя и не относится к полномочиям Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены в статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.П. Привалова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 1 и статьей 2 Закона Республики Татарстан от

8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявителем вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину В.П. Привалову и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 8-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пункты һәм 2 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
20 июнь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин В.П. Привалов шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин В.П. Привалов «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пункты һәм 2 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пункты нигезендә аның гамәле Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән категорияләренә керә торган Россия Федерациясе гражданнарына кагыла.

Дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы гражданнарның адреслы социаль ярдәм чаралары Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә күрсәтелә торган категорияләрен билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин В.П. Привалов — сугыш хәрәкәтләре ветераннары өчен каралган социаль ярдәм күрсәтү чараларын алучы. Гражданнарның әлеге категориясенә күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары күләмен җитәрлек түгел дип санап, шикаять итүче Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм гомуми юрисдикция судына мөрәҗәгать иткән. Ләкин мөрәҗәгатьләре, ул билгеләгәнчә, уңай нәтиҗәгә китермәгән.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3 пункты буенча Россия Федерациясе субъектлары әлеге Федераль законның 14—19 һәм 21 статьяларында билгеләнгән социаль ярдәм күрсәтү чараларына өстәмә рәвештә башка социаль ярдәм күрсәтү чараларын Россия Феде-

рациясе субъектлары законнары һәм алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актлар белән билгели ала.

Шул ук вакытта карала торган Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләре белән социаль ярдәм күрсәтүнең андый өстәмә чаралары билгеләнмәгән, шуның белән, гражданин В.П. Привалов фикеренчә, аның конституциячел хокуклары бозыла. Шулай, мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясенең башка субъектлары үзләренең законнарында социаль ярдәм күрсәтүнең тиешле өстәмә чараларын социаль гаделлек таләпләренә тулысынча җавап бирә торган күләмдә билгеләгәннәр дип күрсәтә. Шул ук вакытта, ул билгеләгәнчә, Татарстан Республикасы Конституциясе белән билгеләнгән югары социаль стандартлар республика законнарында чагылыш тапмаган. Шуның белән, аның фикеренчә, республика закон чыгаручысы тарафыннан каралган җайга салу федераль законнарга каршы килми, ләкин Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә, чөнки анда социаль хокукларның әһәмиятле өлеше бар һәм ул Россия Федерациясенең башка субъектлары белән чагыштырганда социаль гарантияләрнең югарырак дәрәҗәсен беркетә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин В.П. Привалов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктын һәм 2 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законда (2013 елның 21 декабрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) каралганча, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел. Әлеге статьяда каралган вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла, шулай ук федераль бюджеттан өстәмә акча бүлеп бирү өчен нигез булып тормый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республика-

сы Законында гражданнарның Татарстан Республикасында адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган категорияләрен, шулай ук аларны күрсәтүнең конкрет күләмнәрен һәм рәвешләрен билгеләгән.

Татарстан Республикасы Конституция суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законы белән каралган билгеләнеше тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган гражданнарның аерым категорияләренең матди уңайлыкларына ярдәм итү булган хокукый җайга салу максатчан төсмергә ия һәм гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чарасы булып тора, аны билгеләү — Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы. Бу аны бирү нигезләре һәм шартлары социаль-икътисади үсешнең әлеге этабындагы финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата (2016 елның 8 июлендәге 12-О номерлы һәм 2017 елның 12 июлендәге 32-О номерлы билгеләмәләр).

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килеп тора, ул билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентлаштыруда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар; 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что заявительница является опекуном недееспособной гражданки Г.М. Сабитовой — инвалида, страдающего тяжелой формой хронического заболевания, которое входит в Перечень тяжелых форм хронических заболеваний, при которых невозможно совместное проживание граждан в одной квартире, утвержденный постановлением Правительства Российской Федерации от 16 июня 2006 года № 378 (с 1 января 2018 года действует Перечень тяжелых форм хронических заболеваний, при которых невозможно совместное проживание граждан в одной квартире, утвержденный приказом Министерства здравоохранения Российской Федерации от

29 ноября 2012 года № 987н). Гражданка Г.М. Сабитова проживает в жилом помещении, принадлежащем на праве собственности заявительнице, в котором зарегистрированы по месту постоянного жительства еще 4 человека. Распоряжением главы администрации Вахитовского и Приволжского районов Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 18 сентября 2015 года гражданка Г.М. Сабитова поставлена на учет в качестве нуждающейся в улучшении жилищных условий по договору социального найма во внеочередном порядке.

Как указывает заявительница, в связи с тем, что жилое помещение по договору социального найма гражданке Г.М. Сабитовой длительное время не предоставлялось, несмотря на наличие у нее права на внеочередное получение жилья, а также учитывая объективную невозможность дальнейшего совместного с ней проживания, она обратилась в интересах опекаемой в суд. Решением Вахитовского районного суда города Казани гражданке А.Ф. Сабитовой в удовлетворении исковых требований к Исполнительному комитету муниципального образования города Казани, Министерству труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан о предоставлении жилого помещения было отказано.

Заявительница отмечает, что Законом Республики Татарстан от 23 июля 2014 года № 69-ЗРТ в Закон Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» введена статья 8.2, согласно пункту 1 которой инвалидам, страдающим тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в перечне, предусмотренном пунктом 4 части 1 статьи 51 Жилищного кодекса Российской Федерации, а также семьям, имеющим детей-инвалидов, страдающих тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в данном перечне, признанным в установленном порядке нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, вставшим на учет после 1 января 2005 года, предоставляется жилищная субсидия (единовременная денежная выплата) на приобретение жилого помещения.

С заявлением о предоставлении гражданке Г.М. Сабитовой указанной субсидии гражданка А.Ф. Сабитова обращалась в органы исполнительной власти Республики Татарстан и органы местного самоуправления, где ей было отказано. Заявительница обратилась также в суд с иском о предоставлении субсидии, предусмотренной названным законоположением. Однако решением Вахитовского районного суда города Казани, оставленным без изменения апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан, в удовлетворении исковых требований ей было отказано на том основании, что гражданка Г.М. Сабитова не принята на учет нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования.

В связи с этим заявительница неоднократно обращалась в Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан, Исполнительный комитет муниципального образования

города Казани и администрацию Вахитовского и Приволжского районов Исполнительного комитета муниципального образования города Казани с заявлением о принятии гражданки Г.М. Сабитовой на учет в качестве нуждающейся в предоставлении жилого помещения по договору найма жилых помещений жилищного фонда социального использования в Республике Татарстан.

Как отмечает гражданка А.Ф. Сабитова, формирование списков получателей субсидии возможно лишь после утверждения постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан порядка учета граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования. В свою очередь Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан указывает, что жилищная субсидия на приобретение жилого помещения за счет средств бюджета Республики Татарстан может быть предоставлена гражданке Г.М. Сабитовой только при условии постановки ее в установленном порядке на учет в качестве нуждающейся в предоставлении жилого помещения по договору найма жилых помещений жилищного фонда социального использования; вопросы постановки на учет граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, отнесены к компетенции органов местного самоуправления. При этом Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан отмечает, что сведения от Исполнительного комитета муниципального образования города Казани о признании гражданки Г.М. Сабитовой нуждающейся в предоставлении жилого помещения по договору найма жилых помещений жилищного фонда социального использования в министерство не поступали, в связи с чем обеспечить ее жилищной субсидией на приобретение жилого помещения не представляется возможным.

По мнению гражданки А.Ф. Сабитовой, такая ситуация обусловлена тем, что оспариваемые нормы четко не разграничивают полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан и органов местного самоуправления, не определяют с полной ясностью процедуру признания граждан нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования в Республике Татарстан и допускают такое их истолкование в правоприменительной практике, которое препятствует в принятии граждан на соответствующий учет.

В этой связи заявительница считает, что в Республике Татарстан граждане не могут быть признаны нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, а значит, не имеют возможности получить предусмотренную пунктом 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» субсидию, чем нарушаются конституционные права как ее, так и гражданки Г.М. Сабитовой.

На основании изложенного гражданка А.Ф. Сабитова просит

Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 1 статьи 3 и пункт 5 статьи 4 Закона Республики Татарстан от 16 марта 2015 года № 13-ЗРТ «О реализации прав граждан на предоставление им жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования» постольку, поскольку по смыслу, придаваемому им правоприменительной практикой, они четко не разграничивают полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан и органов местного самоуправления, не определяют с полной ясностью процедуру признания граждан нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования в Республике Татарстан и в силу этого не позволяют принимать граждан на соответствующий учет, противоречащими статьям 2, 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 30, 54 (часть первая), 55 и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Согласно части 1 статьи 91.13 Жилищного кодекса Российской Федерации учет граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, осуществляется органом местного самоуправления, а в субъектах Российской Федерации — городах федерального значения Москве, Санкт-Петербурге и Севастополе — органом государственной власти соответствующего субъекта Российской Федерации, если законом соответствующего субъекта Российской Федерации не установлено, что данные полномочия осуществляются органами местного самоуправления внутригородских муниципальных образований.

В соответствии с частью 4 статьи 91.13 Жилищного кодекса Российской Федерации порядок учета граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, в том числе порядок принятия на этот учет, отказа в принятии на него, снятия с него, устанавливается нормативным правовым актом органа государственной власти субъекта Российской Федерации.

Приведенные федеральные нормы нашли свое отражение в Законе Республики Татарстан «О реализации прав граждан на предоставление им жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования». При этом оспариваемые заявительницей положения пункта 1 статьи 3 и пункта 5 статьи 4 данного Закона Республики Татарстан, направленные на определение полномочий Кабинета Министров Республики Татарстан и органов местного самоуправления в сфере жилищных отношений, в рамках реализации которых Кабинет Министров Республики Татарстан постановлением от 7 июня 2018 года № 432 утвердил Порядок учета граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, по своему содержанию и правовому смыслу идентичны положениям, уже закрепленным на федеральном уровне, а следовательно, не устанавливают собственного правового регулирования.

Таким образом, проверка конституционности обжалуемых норм

фактически означала бы оценку названных положений федерального законодательства на их соответствие Конституции Республики Татарстан, что в силу части четвертой статьи 109 Конституции Республики Татарстан и статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан. В связи с этим оспариваемые гражданкой А.Ф. Сабитовой пункт 1 статьи 3 и пункт 5 статьи 4 Закона Республики Татарстан «О реализации прав граждан на предоставление им жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования» сами по себе не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан и согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» данная жалоба не является допустимой.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.Ф. Сабитовой на нарушение конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 3 и пунктом 5 статьи 4 Закона Республики Татарстан от 16 марта 2015 года № 13-ЗРТ «О реализации прав граждан на предоставление им жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке А.Ф. Сабитовой и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 11-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

2018 ел
3 июль
Казан шәһәре

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пункты һәм 4 статьясындагы 5 пункты белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына хокуктан файдалануга сәләтсез гражданка Г.М. Сабитова мәнфәгатьләрендә эш итүче гражданка Ә.Ф. Сабитова «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пункты һәм 4 статьясындагы 5 пункты белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Әлеге Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пункты буенча Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен, шул исәптән әлеге исәпкә кую, исәпкә куюдан баш тарту, аннан төшереп калдыру тәртибен билгеләү торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә керә.

Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләренә керә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — хокуктан файдалануга сәләтсез гражданка Г.М. Сабитованың — Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 16 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлегенә (2018 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 29 ноябрендәге

987н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлеге гамәлдә) кергән хроник авыруның авыр формасы белән авырган инвалидның опекуны. Гражданка Г.М. Сабитова мөрәҗәгать итүченең милек хокукындагы торак урынында яши, анда даими яшәү урыны буенча тагын 4 кеше теркәлгән. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгының 2015 елның 18 сентябрендәге күрсәтмәсе белән гражданка Г.М. Сабитова торак шартларын чираттан тыш тәртиптә социаль наем шартнамәсе буенча яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, торакны чираттан тыш алу хокукы булуына карамастан, гражданка Г.М. Сабитовага социаль наем шартнамәсе буенча торак урын озак вакыт бирелмәгәнгә күрә, шулай ук аның белән бергә яшәүнең объектив мөмкин булмавын исәпкә алып, ул аның опекасында булучының мәнфәгатьләрендә судка мөрәҗәгать иткән. Казан шәһәре Вахитов район суды карары белән гражданка Ә.Ф. Сабитовага Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына торак урын бирү турындагы дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган.

Мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 8.2 статья кертелгән, аның 1 пункты нигезендә билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирелә.

Гражданка Г.М. Сабитовага күрсәтелгән субсидияне бирү турындагы гариза белән гражданка Ә.Ф. Сабитова Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать иткән, анда мөрәҗәгатен кире какканнар. Шикаять бирүче аталган закон нигезләмәсе белән каралган субсидияне бирү турындагы дәгъва белән шулай ук судка мөрәҗәгать иткән. Ләкин Казан шәһәре Вахитов район судының Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган карары белән дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән аңа баш тартылган, сәбәбе — гражданка Г.М. Сабитова социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗларны исәпкә алуга куелмаган.

Шуңа бәйле рәвештә шикаять бирүче берничә тапкыр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясенә гражданка Г.М. Сабитованы Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗ буларак исәпкә кую турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән.

Гражданка Ә.Ф. Сабитова билгеләгәнчә, субсидия алучылар исемлеген формалаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе раслангач кына мөмкин. Үз чиратында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы шуны күрсәтә: Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе гражданка Г.М. Сабитовага аны билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗ буларак исәпкә кую шарты белән генә бирелергә мөмкин; социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую мәсьәләләре җирле үзидарә органнары компетенциясенә керә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы билгеләгәнчә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетыннан гражданка Г.М. Сабитованы социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗ буларак тану турында мәгълүмат килмәгән, шуңа күрә аны торак урын сатып алуга торак субсидиясе белән тәэмин итү мөмкин түгел.

Гражданка Ә.Ф. Сабитова фикеренчә, мондый хәл шуңа бәйле: дәгъвалана торган нормалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен ачык аермыйлар, гражданнарны Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ буларак тану процедурасын тулы ачыклык белән билгеләмиләр һәм аларны хокук куллану практикасында гражданнарны тиешле исәпкә алуга комачаулый торган аңлатуга юл куялар.

Шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасында гражданнар социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ буларак танала алмыйлар, димәк, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пункты белән каралган субсидияне ала алмыйлар, шуның белән аның да, гражданка Г.М. Сабитованың да конституциячел хокуклары бозыла дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Ә.Ф. Сабитова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пунктын һәм 4 статьясындагы 5 пунктын, хокук куллану практикасында аларга бирелә торган мәгънә буенча алар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен ачык аермаганга, гражданнарны Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ буларак тану процедурасын тулы ачыклык белән билгеләмәгәнгә һәм шуннан гражданнарны тиешле исәпкә алуга юл куймаганга күрә, Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 30, 54 (беренче өлеш), 55 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына каршы киләләр дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 91.13 статьясындагы 1 өлеше буенча социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәсе буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗларны исәпкә алу җирле үзидарә органы тарафыннан, ә Россия Федерациясе субъектларында — федераль әһәмияттәге Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Севастополь шәһәрләрендә — тиешле Россия Федерациясе субъекты законы белән әлеге вәкаләтләр шәһәр эчендәге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләнмәгән булса, тиешле Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Торак кодексының 91.13 статьясындагы 4 өлеше нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе, шул исәптән әлеге исәпкә кую, исәпкә куюдан баш тарту, аннан төшереп калдыру тәртибе Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органы норматив хокукый акты белән билгеләнә.

Китерелгән федераль нормалар «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законында үз чагылышын табалар. Шул ук вакытта әлеге Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пункты һәм 4 статьясындагы 5 пунктының торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен (аларны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2018 елның 7 июнендәге карары белән Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен раслаган) билгеләүгә юнәлгән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган

нигезләмәләре үзләренең эчтәлеге һәм хокукый мәгънәсе буенча федераль дәрәҗәдә беркетелгән нигезләмәләр белән тәңгәл, димәк, мөстәкыйль хокукый җайга салуны билгеләмиләр.

Шулай итеп, дәгъвалана торган нормаларның конституциячеллеген тикшерү асылда аталган федераль законнар нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвенә бәя бирүне аңлатыр иде, бу исә Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясындагы дүртенче өлеше һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми. Шуңа бәйле рәвештә «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының гражданка Ә.Ф. Сабитова тарафыннан дәгъвалана торган 3 статьясындагы 1 пункты һәм 4 статьясындагы 5 пунктының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә әлеге шикаять карала алмый.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пункты һәм 4 статьясындагы 5 пункты белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Ә.Ф. Сабитовага һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 11-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.И. Симакова на нарушение его конституционных прав и свобод частью 2 статьи 1 и частью 3 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания "Ветеран труда"»**

5 июля
2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Ф.Р. Волковой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина В.И. Симакова,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин В.И. Симаков с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод частью 2 статьи 1 и частью 3 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания "Ветеран труда"» (далее также — Закон Республики Татарстан).

В соответствии с частью 2 статьи 1 данного Закона Республики Татарстан под ведомственными знаками отличия, дающими право на присвоение звания «Ветеран труда», понимаются ведомственные награды за заслуги в труде (службе) и продолжительную работу (службу) не менее 15 лет в соответствующей сфере деятельности (отрасли экономики), учрежденные федеральными органами исполнительной власти, иными федеральными государственными органами, государственными корпорациями, и награждение которыми осуществлялось в порядке, установленном указанными органами и организациями.

Согласно части 3 статьи 9 указанного Закона Республики Татарстан орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченный в области социальной защиты, в пределах своей компетенции вправе издавать методические рекомендации по вопросам практики присвоения звания «Ветеран труда».

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что заявитель был награжден нагрудным знаком «Отличный пограничник», который, по его мнению, является ведомственным знаком отличия в труде и дает право на присвоение звания «Ветеран труда». В обоснование своего довода гражданин В.И. Симаков ссылается на письмо Министерства труда Российской Федерации от 7 октября 1998 года № 5635-КС «О ведомственных знаках отличия в труде, учитываемых при присвоении звания "Ветеран труда"», согласно которому нагрудные знаки «Отличный пограничник» и «Отличник погранвойск» были отнесены к таким ведомственным знакам отличия в труде. В Перечень ведомственных знаков отличия в труде, утвержденный приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 29 июня 2012 года № 481, нагрудный знак «Отличный пограничник» не входит, но ранее

в него входил нагрудный знак «Отличник погранвойск», утвержденный приказом КГБ при СМ СССР от 8 апреля 1969 года № 53 и приравненный к нагрудному знаку «Отличный пограничник».

Отделом социальной защиты Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан в Приволжском районе муниципального образования города Казани гражданину В.И. Симакову в приеме документов на присвоение звания «Ветеран труда» отказано. Такое решение мотивировано тем, что Положение об этом нагрудном знаке, утвержденное приказом КГБ СССР от 3 августа 1957 года, не содержит сведений о том, что нагрудный знак «Отличный пограничник» является ведомственным знаком отличия в труде, этот нагрудный знак являлся лишь видом поощрения в период выполнения воинского долга — прохождения заявителем срочной службы в рядах Советской Армии, а поэтому не является поощрением за особые отличия в труде. Не согласившись с принятым решением, гражданин В.И. Симаков обратился в суд, однако решением Ново-Савиновского районного суда города Казани ему в удовлетворении исковых требований к Министерству труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан было отказано.

Заявитель отмечает, что отказ основан на оспариваемом положении части 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан, в силу которого нагрудный знак «Отличный пограничник» не является ведомственным знаком отличия в труде, хотя на момент принятия в отношении него правоприменительных решений действовала иная редакция, но требование о наличии ведомственного знака отличия в труде для присвоения звания «Ветеран труда» осталось неизменным.

Гражданин В.И. Симаков полагает, что обжалуемая норма части 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан, положенная в основу аргументации правоприменительных решений по его делу, в силу которой нагрудные знаки лиц, отличившихся при несении военной службы, не признаются ведомственными нагрудными знаками, позволяет правоприменительным органам придавать ей толкование, противоречащее Конституции Республики Татарстан, что нарушает его конституционные права.

По мнению заявителя, часть 3 статьи 9 Закона Республики Татарстан, наделяя орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченный в области социальной защиты, правом издания только методических рекомендаций по вопросам практики присвоения звания «Ветеран труда», фактически предоставляет ему право принятия обязательного для исполнения перечня ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении этого звания. В этой связи гражданин В.И. Симаков считает, что, поскольку этот перечень носит обязательный, а не рекомендательный характер, имеющийся у него нагрудный знак, не включенный в перечень, препятствует получению звания «Ветеран труда», чем нарушаются его конституционные права.

На основании изложенного гражданин В.И. Симаков просит Конституционный суд Республики Татарстан признать часть 2 статьи 1 и часть 3 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения зва-

ния “Ветеран труда”» не соответствующими статьям 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 54 (часть первая), 58 (часть вторая) и 63 (часть первая) Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с Федеральным законом от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах» ветеранами труда являются лица, имеющие удостоверение «Ветеран труда» и награжденные в том числе и ведомственными знаками отличия в труде, а также имеющие соответствующий трудовой стаж, необходимый для назначения пенсии по старости или за выслугу лет (подпункты 1 и 2 пункта 1 статьи 7). В силу пункта 4 статьи 7 данного Федерального закона порядок и условия присвоения звания «Ветеран труда» определяются законами и иными нормативными правовыми актами субъектов Российской Федерации.

Как отметил Конституционный Суд Российской Федерации, установление порядка и условий присвоения звания «Ветеран труда» и, соответственно, определение того, какие знаки отличия в труде подлежат учету для присвоения указанного звания, относится к компетенции субъектов Российской Федерации (Определение от 21 ноября 2013 года № 1821-О). Таким образом, субъекты Российской Федерации при осуществлении правового регулирования в рассматриваемой сфере вправе самостоятельно решать вопросы отнесения тех или иных знаков к ведомственным знакам отличия в труде, а также определять перечень таких знаков.

В Республике Татарстан основания для присвоения звания «Ветеран труда» определены в Законе Республики Татарстан «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”». Из содержания оспариваемого положения части 2 статьи 1 названного Закона Республики Татарстан основанием для присвоения звания «Ветеран труда» является награждение ведомственными знаками отличия за заслуги в труде и продолжительную работу не менее 15 лет в соответствующей сфере деятельности, учрежденными федеральными органами исполнительной власти, иными федеральными государственными органами, государственными корпорациями, и награждение которыми осуществлялось в порядке, установленном указанными органами и организациями.

Во исполнение Закона Республики Татарстан Кабинет Министров Республики Татарстан принял постановление от 13 марта 2012 года № 210 «О порядке и условиях отнесения государственных и иных органов к перечню органов, ведомственные знаки отличия в труде которых учитываются при присвоении звания “Ветеран труда” в Республике Татарстан», утвердил перечень этих органов и организаций, а также установил, что перечень ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, определяется Министерством труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан. В пределах предоставленных ему вышеупомянутыми правовыми актами полномочий министерство своим приказом от 29 июня 2012 года № 481 утвердило перечень, в который не был включен нагрудный знак «Отличный пограничник».

Что касается письма Министерства труда Российской Федерации от 7 октября 1998 года № 5635-КС «О ведомственных знаках

отличия в труде, учитываемых при присвоении звания “Ветеран труда”», на которое ссылается заявитель, то оно было отозвано письмом Министерства здравоохранения и социального развития Российской Федерации от 2 июня 2008 года № 3854-ЮВ и его использование в работе органов исполнительной власти субъектов Российской Федерации не представляется возможным. Тем самым на федеральном уровне граждане, награжденные нагрудными знаками «Отличный пограничник» и «Отличник погранвойск», к категории лиц, имеющих право на присвоение звания «Ветеран труда», не отнесены.

Относительно доводов заявителя в части полномочий Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан как органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в области социальной защиты, следует отметить, что они не ограничиваются изданием методических рекомендаций по вопросам практики присвоения звания «Ветеран труда», как это предусмотрено обжалуемой частью 3 статьи 9 Закона Республики Татарстан. На основании части 2 статьи 43 Закона Республики Татарстан от 6 апреля 2005 года № 64-ЗРТ «Об исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан» министерство вправе издавать в пределах своей компетенции нормативные правовые акты, имеющие общеобязательный характер, не только в случаях, установленных законами Республики Татарстан, но и нормативными правовыми актами Президента Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан.

Обжалуемые заявителем положения части 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан, касающиеся отнесения ведомственных наград к ведомственным знакам отличия в труде, учитываемым при присвоении звания «Ветеран труда», уже являлись предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан. Согласно позиции Конституционного суда Республики Татарстан, неоднократно высказанной им в своих решениях, установленное в части 2 статьи 1 оспариваемого Закона Республики Татарстан условие об отнесении к ведомственным знакам отличия в труде наград центральных органов только тех общественных объединений и организаций, которые участвуют (участвовали) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, производно от публично-правовой природы отношений, связанных с присвоением звания «Ветеран труда», поскольку присвоение лицу данного звания влечет возникновение обязанности соответствующего государственного органа по предоставлению ветерану труда мер социальной поддержки, финансируемых за счет средств бюджета (постановление от 25 марта 2014 года № 58-П, определения от 8 апреля 2014 года № 8-О, от 2 июля 2015 года № 5-О).

Таким образом, оспариваемые заявителем положения основаны на нормах федерального законодательства, не нарушают конституционные принципы равенства и справедливости, не ограничивают права граждан, в том числе и гражданина В.И. Симакова, и, следовательно, не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с

пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявителя не является допустимой. Разрешение же вопроса о возможности отнесения нагрудных знаков к ведомственным знакам отличия, дающим право на присвоение звания «Ветеран труда», не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина В.И. Симакова на нарушение его конституционных прав и свобод частью 2 статьи 1 и частью 3 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленных заявителем вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину В.И. Симакову и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 12-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше һәм 9 статьясындагы 3 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.И. Симаков шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
5 июль
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин В.И. Симаков шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин В.И. Симаков «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 1 статьясындагы 2 өлеше һәм 9 статьясындагы 3 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Әлеге Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары дигәндә, федераль башкарма хакимият органнары, башка федераль дәүләт органнары, дәүләт корпорацияләре тарафыннан гамәлгә куелган һәм алар белән бүләкләү күрсәтелгән органнар һәм оешмалар билгеләгән тәртиптә башкарылган, эштәге (хезмәттәге) казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә (икътисад тармагында) кимендә 15 ел дәвамында эшләгән (хезмәт иткән) өчен ведомство бүләкләре дип аңларга кирәк.

Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 3 өлеше буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәҗрибәсе мәсьәләләре буенча үз компетенциясе чикләрендә методик күрсәтмәләр чыгарырга хокуклы.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче «Бик яхшы чик сакчысы» күкрәк тамгасы белән бүләкләнгән булган, ул, аның фикеренчә, хезмәттәге ведомство аерымлык тамгасы булып тора һәм «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә. Үз фикерен дәлилләп, гражданин В.И. Симаков «“Хезмәт ветераны” исеме бирелгәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары турында» Россия Федерациясе Хезмәт

министрлыгының 1998 елның 7 октябрендәге 5635-КС номерлы хатына сылтама бирә, аның буенча «Бик яхшы чик сакчысы» һәм «Чик буе гаскәрләре отличнигы» күкрәк тамгалары шундый хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исәбенә кергән булган. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 29 июнендәге 481 номерлы боерыгы белән расланган Хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлегенә «Бик яхшы чик сакчысы» күкрәк тамгасы керми, ләкин элегрәк аңа СССР МС каршындагы КГБның 1969 елның 8 апрелендәге 53 номерлы боерыгы белән расланган һәм «Бик яхшы чик сакчысы» күкрәк тамгасына тиңләштерелгән «Чик буе гаскәрләре отличнигы» күкрәк тамгасы кергән.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Идел буе районындагы социаль яклау бүлеге тарафыннан «Хезмәт ветераны» исеме бирелү өчен документлар кабул итүдән гражданин В.И. Симаковка баш тартылган. Мондый карар шуның белән нигезләнгән: СССР КГБның 1957 елның 3 августындагы боерыгы белән расланган әлеге күкрәк тамгасы турындагы Нигезләмәдә «Бик яхшы чик сакчысы» күкрәк тамгасы хезмәттәге ведомство аерымлык тамгасы булып тора дигән мәгълүмат юк, әлеге күкрәк тамгасы хәрби бурыч үтәгәндә — мөрәҗәгать итүче Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә кызыксындыру бүләге генә булган, шуңа күрә хезмәттәге аерым уңышлар өчен бүләк булып тормый. Кабул ителгән карар белән ризалашмыйча, гражданин В.И. Симаков судка мөрәҗәгать иткән, ләкин Казан шәһәре Яңа Савин район суды карары белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән аңа баш тартылган.

Мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, үтенечен кире кагу Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең дәгъвалана торган нигезләмәсенә таянган, аның буенча «Бик яхшы чик сакчысы» күкрәк тамгасы хезмәттәге ведомство аерымлык тамгасы булып тормый, аңа карата хокук куллану карарлары кабул ителү моментына башка редакция гамәлдә булса да, «Хезмәт ветераны» исеме бирелү өчен хезмәттәге ведомство аерымлык тамгасы булу кирәклеге турындагы таләп үзгәрмәгән.

Гражданин В.И. Симаков санавынча, Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең аның эше буенча хокук куллану карарларындагы хәрби хезмәт үткәндә башкалардан аерылган затларның күкрәк тамгалары ведомство күкрәк тамгалары булып танылмый дигән дәлилләрнең нигезен тәшкил иткән дәгъвалана торган нормасы хокук куллану органнарына аңа Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә торган аңлатма бирүгә юл куя, бу исә аның конституциячел хокукларын боза.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 3 өлеше Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле ор-

ганына «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәҗрибәсе мәсьәләләре буенча бары тик методик күрсәтмәләр чыгару хокукын биреп, фактта үтәү өчен мәҗбүри булган әлеге исем бирелгәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлеген кабул итү хокукын бирә. Шуңа бәйле рәвештә гражданин В.И. Симаков, әлеге исемлек тәкъдим булмыйча, мәҗбүри характерга ия булганга күрә, исемлеккә кермәгән аның күкрәк тамгасы «Хезмәт ветераны» исемен алуга комачаулый, шуның белән аның конституциячел хокуклары бозыла, дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин В.И. Симаков Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешен һәм 9 статьясындагы 3 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) һәм 63 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Хезмәт ветераны» таныклыгы булган һәм шул исәптән хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнгән, шулай ук картлык буенча яисә озак еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле хезмәт стажы булган затлар хезмәт ветераннары була (7 статьяның 1 пунктындагы 1 һәм 2 пунктчалар). Әлеге Федераль законның 7 статьясындагы 4 пункты буенча «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибен һәм шартларын билгеләү һәм әлеге исем бирү өчен хезмәттәге аерымлыкның кайсы тамгалары исәпкә алынырга тиеш булуын билгеләү Россия Федерациясе субъектлары компетенциясенә керә (2013 елның 21 ноябрендәге 1821-О номерлы Билгеләмә). Шулай итеп, Россия Федерациясе субъектлары карала торган өлкәдә хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда теге яки бу тамгаларны хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исәбенә кертү мәсьәләләрен мөстәкыйль хәл итәргә, шулай ук андый тамгалар исемлеген билгеләргә хокуклы.

Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен нигезләр «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән. Аталган Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең дәгъвалана торган нигезләмәсе эчтәлегеннән «Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен нигез булып федераль башкарма хакимият органнары, башка федераль дәүләт органнары, дәүләт корпорацияләре тарафыннан гамәлгә куелган һәм алар белән бүләкләү күрсәтелгән органнар һәм оешмалар билгеләгән тәртиптә башкарылган, эштәге казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә кимендә 15 ел дәвамында эшләгән өчен ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнү тора.

Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты «Дәүләт органнарын һәм башка органнарны хезмәттәге ведомство аерымлык билгеләре Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исемен биргәндә исәпкә алына торган органнар исемлегенә кертү тәртибе һәм шартлары турында» 2012 елның 13 мартындагы 210 номерлы карарын кабул иткән, әлеге органнар һәм оешмалар исемлеген раслаган, шулай ук Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исемен биргәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлеге Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә дип билгеләгән. Югарыда аталган хокукый актлар белән үзенә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә министрлык 2012 елның 29 июнендәге 481 номерлы боерыгы белән исемлекне раслаган, аңа «Бик яхшы чик сакчысы» күкрәк тамгасы кертелмәгән.

Мөрәҗәгать итүче сылтама ясаган «“Хезмәт ветераны” исеме бирелгәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары турында» Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгының 1998 елның 7 октябрендәге 5635-КС номерлы хатына килгәндә, ул Россия Федерациясе Сәламәтлек һәм социаль үсеш министрлыгының 2008 елның 2 июнендәге 3854-ЮВ номерлы хаты белән гамәлдән чыгарылган һәм аны Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшендә куллану мөмкин түгел. Шуның белән «Бик яхшы чик сакчысы» һәм «Чик буе гаскәрләре отличнигы» күкрәк тамгалары белән бүләкләнгән гражданнар федераль дәрәҗәдә «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукына ия булган затлар категориясенә кермиләр.

Мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы буларак вәкаләтләре өлешендәге дәлилләренә килгәндә, шуны билгеләп үтәргә кирәк: алар Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы дәгъвалана торган 3 өлеше белән каралган «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәҗрибәсе мәсьәләләре буенча методик күрсәтмәләр чыгару белән чикләнмиләр. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 43 статьясындагы 2 өлеше нигезендә министрлык үз компетенциясе чикләрендә гомуммәҗбүри характердагы норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы законнарында гына түгел, ә Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда чыгарырга хокуклы.

Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең ведомство бүләкләрен «Хезмәт ветераны» исеме бирелгәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исәбенә кертүгә бәйле мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган нигезләмәләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. Татарстан Республикасы Конституция судының үз карарларында берничә

тапкыр әйтелгән позициясе буенча дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән хезмәттәге ведомство аерымлык тамгаларына дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашучы (катнашкан) иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның үзәк органнары бүләкләрен генә кертү турындагы шарт «Хезмәт ветераны» исеме бирелүгә бәйле мөнәсәбәтләрнең гавами-хокукый табигатеннән килеп чыга, чөнки затка бу исемне бирү тиешле дәүләт органының ветеранга бюджет акчалары исәбеннән финанслана торган социаль ярдәм чараларын күрсәтү йөкләмәсен барлыкка китерә (2014 елның 25 мартындагы 58-П номерлы карар, 2014 елның 8 апрелендәге 8-О номерлы, 2015 елның 2 июлендәге 5-О номерлы билгеләмәләр).

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган нигезләмәләр федераль законнар нормаларына таянган, тигезлек һәм гаделлек конституциячел принципларын бозмыйлар, гражданнарның, шул исәптән гражданин В.И. Симаковның хокукларын чикләмиләр һәм, димәк, аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый. Күкрәк тамгаларын «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары исәбенә кертү мөмкинлеге турындагы мәсьәләне хәл итү исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше һәм 9 статьясындагы 3 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.И. Симаков шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин В.И. Симаковка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 12-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки В.М. Омаровой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 2, 3 и 6 Порядка информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат», названным постановлением в целом, а также абзацем первым пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524 «О порядке опубликования и вступления в силу постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан»**

11 июля
2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки В.М. Омаровой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка В.М. Омарова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 2, 3 и 6 Порядка информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат» (далее также — Порядок), названным постановлением в целом по порядку введения его в действие, а также абзацем первым пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524 «О порядке опубликования и вступления в силу постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан» (далее также — постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524).

Обжалуемый Порядок определяет информационное взаимодействие министерств, ведомств и других организаций с применением интегрированных информационных технологий предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат в Республике Татарстан с целью обеспечения оперативного предоставления гражданам жилищно-коммунальных субсидий и ежемесячных денежных выплат.

В пункте 2 Порядка перечисляются основные организации — участники информационного взаимодействия.

Согласно пункту 3 Порядка взаимодействие организаций-участников осуществляется на основании соглашений, заключенных с Министерством труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан (его территориальными органами) или с государственным казенным учреждением «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)» (его отделениями). Кроме того, в нем предусматриваются конкретные требования к содержанию соглашения.

Пунктом 6 Порядка предусмотрена последовательность осуществления информационного взаимодействия организаций-участников с указанием объема информации, которая включает в себя источник информации, краткое описание выполняемой операции и передаваемой информации, а также форму, срок ее представления и получателей информации.

Абзац первый пункта 4 обжалуемого постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524 устанавливает, что постановления и распоряжения Кабинета Министров Республики Татарстан, затрагивающие права, свободы и обязанности человека и гражданина, вступают в силу на территории Республики Татарстан не ранее чем через десять дней после их официального опубликования.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница является инвалидом, состоит на учете в отделении № 16 государственного казенного учреждения «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)» в Верхнеуслонском муниципальном районе Республики Татарстан и с 1 февраля 2014 года стала получателем субсидии-льготы на оплату жилого помещения и коммунальных услуг на основании Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» и в соответствии с Положением о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденным постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126. Однако с декабря 2015 года предоставление субсидии-льготы заявительнице было приостановлено в связи с неуплатой ею жилищно-коммунальной услуги по вывозу твердых бытовых отходов. Информация о задолженности поступила в государственное казенное учреждение «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)» от общества с ограниченной ответственностью «ЭкоАвтоТрейд» во исполнение заключенного между ними Соглашения об информационном взаимодействии от 21 июля 2014 года.

Решением Верхнеуслонского районного суда Республики Татарстан, оставленным без изменения апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан, в удовлетворении исковых требований прокурору, действовавшему в интересах гражданки В.М. Омаровой, о признании незаконными действий, выразившихся в при-

остановлении предоставления субсидии-льготы на оплату жилья и коммунальных услуг, было отказано. Определением судьи Верховного суда Республики Татарстан в передаче кассационной жалобы для рассмотрения в судебном заседании кассационной инстанции Верховного суда Республики Татарстан также было отказано.

Заявительница отмечает, что решения судов общей юрисдикции основаны на оспариваемых положениях Порядка, определяющих информационное взаимодействие министерств, ведомств и других организаций при предоставлении субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг. Организации, предоставляющие населению жилищно-коммунальные услуги по договорам, заключенным непосредственно с гражданами, проживающими в индивидуальном жилищном фонде или многоквартирном жилищном фонде, пунктом 2 Порядка отнесены к основным организациям — участникам информационного взаимодействия. Она считает, что оспариваемым Порядком не урегулировано, каким образом указанные организации должны подтверждать применимость (относимость) представляемой ими информации по отношению к конкретному гражданину (наличие соответствующих правоотношений: заключение договора и его действие в момент представления информации, а также информация о его расторжении или изменении). По мнению гражданки В.М. Омаровой, обжалуемые нормы Порядка не отвечают требованиям ясности, недвусмысленности и определенности правового регулирования и тем самым нарушают ее конституционные права.

Заявительница также полагает, что постановление Кабинета Министров Республики Татарстан «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат» еще не вступило в силу, поскольку как в действующей, так и во всех остальных редакциях дата вступления его в силу не установлена и лишь в пункте 2 задним числом Министерству труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан поручено обеспечить введение с 1 января 2005 года механизма по перечислению субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат на лицевые (вкладные) счета граждан. По ее мнению, словосочетание «не ранее», содержащееся в постановлении Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524, не означает, что нормативные акты вступают в силу именно через 10 дней, и допускает любую последующую дату. Заявительница считает, что в ее конкретном деле был применен нормативный акт, не вступивший в силу, чем также были нарушены ее конституционные права.

На основании изложенного гражданка В.М. Омарова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункты 2, 3 и 6 Порядка информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на

оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат», названное постановление в целом по порядку введения его в действие, а также абзац первый пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524 «О порядке опубликования и вступления в силу постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан» не соответствующими статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 54 (часть первая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с пунктом 1 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» меры социальной поддержки по оплате жилищно-коммунальных услуг предоставляются в денежной форме. Вышеназванным постановлением утверждено также Положение о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, которое предусматривает получение государственным казенным учреждением «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)» на основании межведомственных запросов, в том числе в электронной форме с использованием системы межведомственного информационного взаимодействия, сведений, необходимых для принятия решения о предоставлении субсидии-льготы. В целях обеспечения оперативного предоставления гражданам жилищно-коммунальных субсидий и ежемесячных денежных выплат Кабинет Министров Республики Татарстан в оспариваемом Порядке установил последовательность информационного взаимодействия министерств, ведомств и других организаций в рамках предоставления всех видов субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг, включая и субсидии-льготы.

Пунктом 6 Порядка определен механизм взаимодействия, в частности, организаций, предоставляющих населению жилищно-коммунальные услуги по договорам, заключенным непосредственно с гражданами, проживающими в индивидуальном жилищном фонде или многоквартирном жилищном фонде, и территориальных органов Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан в муниципальных образованиях или государственного казенного учреждения «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)». Так, в силу подпункта 8 пункта 6 Порядка к числу сведений, необходимых для передачи организации, предоставляющей населению жилищно-коммунальные услуги по договорам, заключенным непосредственно с гражданами, проживающими в индивидуальном жилищном фонде или многоквартирном жилищном фонде, в государственное казенное учреждение «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)», относятся, в частности, сведения о начислениях за фактически оказанные жилищно-коммунальные услуги, факте отключения коммунальных услуг, факте подключения коммунальных услуг. При этом оспариваемый пункт 3 Порядка, регламентирующий обязательность заключения

соглашений о порядке взаимодействия организаций-участников, перечисленных в рассматриваемом пункте 2, с указанными ведомствами, четко устанавливает, что такое соглашение должно включать в себя ответственность его участников за представление несвоевременной (недостоверной) информации.

Применительно к поставленному заявительницей вопросу это означает, что оспариваемые нормы в их взаимосвязи и, исходя из их системного толкования, не допускают возможности передачи организации, предоставляющей населению жилищно-коммунальные услуги по договорам, заключенным непосредственно с гражданами, проживающими в индивидуальном жилищном фонде или многоквартирном жилищном фонде, в уполномоченный орган сведений о фактически не предоставляемых услугах или услугах, по которым договор с гражданами не заключен. Кроме того, пункт 6 Порядка уже был предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан, который указал, что по своей правовой природе установленный указанными нормами перечень сведений, передаваемых управляющими организациями в орган, принимающий решение о предоставлении гражданам субсидий-льгот, является исчерпывающим и исключает возможность его произвольного истолкования. Сам по себе порядок информационного обмена направлен лишь на оперативное предоставление гражданам жилищно-коммунальных субсидий, на обеспечение единообразия в правоприменительной практике и не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан (определение от 28 декабря 2016 года № 27-О).

Тем самым оспариваемые нормы не содержат неопределенности в вопросе об их соответствии Конституции Республики Татарстан и сами по себе не могут расцениваться как нарушающие конституционные права граждан, в том числе и заявительницы в указанном ею аспекте.

Исследование же вопроса о том, заключался ли с ней договор на оказание рассматриваемой жилищно-коммунальной услуги, оценка правомерности его заключения, равно как и проверка обоснованности правоприменительных решений, вынесенных по ее делу, предполагают исследование фактических обстоятельств дела, что не относится к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Относительно довода заявительницы, касающегося применения в ее конкретном деле не вступившего в силу нормативного правового акта, Конституционный суд Республики Татарстан отмечает, что в соответствии с Федеральным законом от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» законы и иные нормативные правовые акты субъекта Российской Федерации по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина вступают в силу не ранее чем через десять дней после их официального опубликования (пункт 5 статьи 8). Указанное правовое регулирование нашло

свое отражение и в Законе Республики Татарстан от 31 октября 2002 года № 21-ЗРТ «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина», согласно статье 6 которого нормативные правовые акты Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина вступают в силу через 10 дней после их официального опубликования, если самими актами не установлен иной, более поздний, срок вступления их в силу.

Следовательно, формулировка, указанная в оспариваемом абзаце первом пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524, основана на нормах федерального и республиканского законодательства.

Таким образом, обжалуемый заявительницей абзац первый пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524 сам по себе также не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» обращение заявительницы не является допустимым.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки В.М. Омаровой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 2, 3 и 6 Порядка информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат», названным постановлением в целом по порядку введения его в действие, а также абзацем первым пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524 «О порядке опубликования и вступления в силу постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан», поскольку она не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», в соответствии с которыми жалоба признается допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке В.М. Омаровой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 14-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең 2, 3 һәм 6 пунктлары, тулысынча аталган карар, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карарының 4 пунктындагы беренче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка В.М. Омарова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
11 июль
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка В.М. Омарова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка В.М. Омарова «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 2, 3 һәм 6 пунктлары, гамәлгә кертү тәртибе буенча тулысынча аталган карар, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карарының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карары) 4 пунктындагы беренче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган Тәртип гражданнарга торак-коммуналь субсидияләрне һәм айлык акчалата түләүләрне оператив бирүне

тәэмин итү максатында министрлыклар, ведомстволар һәм башка оешмаларның Татарстан Республикасында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирүдә интеграль мәгълүмат технологияләрен кулланып, мәгълүмати хезмәттәшлек итүен билгели.

Тәртипнең 2 пунктында мәгълүмати хезмәттәшлек итүдә катнашучы төп оешмалар саналып чыга.

Тәртипнең 3 пункты буенча катнашучы оешмалар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (аның территориаль органнары) яки «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (аның бүлекләре) белән төзелгән килешүләр нигезендә хезмәттәшлек итә. Моннан тыш, анда килешү эчтәлегенә карата конкрет таләпләр каралган.

Тәртипнең 6 пункты белән мәгълүмат чыганагын, башкарыла торган операциянең һәм тапшырыла торган мәгълүматның кыскача тасвирламасын, шулай ук формасын, тапшыру срогын һәм мәгълүмат алучыларны үз эченә алган мәгълүмат күләмен күрсәтеп, катнашучы оешмаларның мәгълүмати хезмәттәшлек итү эзлеклелеге каралган.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы дәгъвалана торган карарының 4 пунктындагы беренче абзацы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган карарлары һәм күрсәтмәләре рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң кимендә ун көн узгач Татарстан Республикасы территориясендә үз көченә керәләр, дип билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — инвалид, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районындагы 16 номерлы бүлегендә исәптә тора һәм 2014 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә буенча торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия ала. Ләкин каты көнкүреш калдыкларын чыгару буенча торак-коммуналь хезмәт өчен түләмәү сәбәпле, 2015 елның декабреннән мөрәҗәгать итүчегә ташлама-субсидияне бирү туктатып торылган. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә бурыч турында мәгълүмат «ЭкоАвтоТрейд» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән алар арасында 2014 елның 21 июлендә төзелгән Мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында килешүне үтәү йөзеннән килгән.

Татарстан Республикасы Югары Ослан район судының Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган карары белән гражданка В.М. Омарова мәнфәгатьләрендә эш иткән прокурорга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия бирү туктатылып торуда чагылган гамәлләрне законсыз дип тану турындагы дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган. Татарстан Республикасы Югары суды судьясы билгеләмәсе белән кассация шикаятен Татарстан Республикасы Югары судының кассация инстанциясе утырышында карауга тапшырудан шулай ук баш тартылган.

Мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, гомуми юрисдикция судлары карарлары Тәртипнең торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен субсидияләр бирелгәндә министрлыклар, ведомстволар һәм башка оешмаларның мәгълүмати хезмәттәшлек итүен билгеләүче дәгъвалана торган нигезләмәләренә таянган. Индивидуаль торак фондта яки күпфатирлы торак фондта яшәүче гражданнар белән турыдан-туры төзелгән килешүләр буенча халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмалар Тәртипнең 2 пункты белән мәгълүмати хезмәттәшлек итүдә катнашучы төп оешмалар исәбенә кертелгән. Ул санаганча, дәгъвалана торган Тәртип белән күрсәтелгән оешмаларның алар тапшыра торган мәгълүматның конкрет граждан мөнәсәбәтендә кулланылуын (кагылышлы булуын) (тиешле хокукый мөнәсәбәтләрнең булуы: килешү төзү һәм мәгълүмат тапшыру моментына аның гамәлдә булуы, шулай ук аны өзү яки үзгәртү турында мәгълүмат) ни рәвешле расларга тиешлеге җайга салынмаган. Гражданка В.М. Омарова фикеренчә, Тәртипнең дәгъвалана торган нормалары хокукый җайга салуда ачыклык, мәгънә берлеге һәм билгелелек булу таләпләренә җавап бирмиләр һәм шуның белән аның конституциячел хокукларын бозалар.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары үз көченә кермәгән дип саный, чөнки гамәлдәге редакциясендә дә, башкаларында да аның үз көченә керү көне билгеләнмәгән һәм 2 пунктта гына арткы число белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына 2005 елның 1 гыйнварыннан торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләрне һәм айлык акчалата түләүләрне гражданнарның шәхси (кертем) хисапларына күчерү механизмын кертүне тәэмин итәргә йөкләнгән. Аның фикеренчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карарындагы «кимендә ун көн узгач» сүзләре норматив актлар нәкъ 10 көннән соң үз көченә керәләр дигәнне аңлатмыйлар һәм аннан соңгы теләсә кайсы датаны рөхсәт итәләр. Мөрәҗәгать итүче аның конкрет эшендә үз көченә кермәгән норматив акт кулланылган, шуның белән аның конституциячел хокуклары шулай ук бозылган, дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка В.М. Омарова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең 2, 3 һәм 6 пунктларын, гамәлгә кертү тәртибе буенча тулысынча аталган карарны, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карарының 4 пунктындагы беренче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карарының 1 пункты нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары акчалата бирелә. Югарыда аталган карар белән шулай ук Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә расланган, ул «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә ташлама-субсидия бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар алуны күздә тота. Гражданнарга торак-коммуналь субсидияләрне һәм айлык акчалата түләүләрне оператив бирүне тәэмин итү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты дәгъвалана торган Тәртиптә министрлыклар, ведомстволар һәм башка оешмаларның торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләрне кертеп, субсидияләрнең бөтен төрләрен бирү кысаларында мәгълүмати хезмәттәшлек итү эзлеклелеген билгеләгән.

Тәртипнең 6 пункты белән, аерым алганда, индивидуаль торак фондта яки күпфатирлы торак фондта яшәүче гражданнар белән турыдан-туры төзелгән килешүләр буенча халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль берәмлекләрдәге территориаль органнарының яки «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең хезмәттәшлек итү механизмы билгеләнгән. Шулай, Тәртипнең 6 пунктындагы 8 пунктчасы нигезендә индивидуаль торак фондта яки күпфатирлы

торак фондта яшәүче гражданнар белән турыдан-туры төзелгән килешүләр буенча халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмага, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә тапшырылырга тиешле мәгълүматлар исәбенә, аерым алганда, гамәлдә күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр өчен хисапланган түләүләр, коммуналь хезмәтләрне өздерү факты, коммуналь хезмәтләрне тоташтыру факты керә. Шул ук вакытта Тәртипнең карала торган 2 пунктында саналган катнашучы оешмаларның күрсәтелгән ведомстволар белән хезмәттәшлек итү тәртибе турында килешүләр төзү тиешлеген регламентлаштыручы дәгъвалана торган 3 пункты андый килешүдә катнашучыларның үз вакытында булмаган (ышанычсыз) мәгълүмат тапшырган өчен җаваплы булуын ачык билгели.

Мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләгә килгәндә, бу шуны аңлата: дәгъвалана торган нормалар үзара бәйләнештә һәм аларны системалы аңлатудан чыгып, индивидуаль торак фондта яки күпфатирлы торак фондта яшәүче гражданнар белән турыдан-туры төзелгән килешүләр буенча халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмага, вәкаләтле органга гамәлдә күрсәтелми торган хезмәтләр яки гражданнар белән килешү төзелмәгән хезмәтләр турында мәгълүматлар тапшыру мөмкинлегенә юл куймыйлар. Моннан тыш, Тәртипнең 6 пункты Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде, ул күрсәткәнчә, үзенең хокукый табигате буенча гражданнарга ташлама-субсидияләр бирү турында карар кабул итә торган органга идарәче оешмалар тапшыра торган күрсәтелгән нормалар белән билгеләнгән мәгълүматлар исемлеге тулы һәм аны ирекле аңлату мөмкинлегенә юл куелмаган. Мәгълүмат алмашу тәртибе үзеннән-үзе бары тик гражданнарга торак-коммуналь субсидияләрне оператив бирүгә, хокук куллану практикасында бертөрлелекне тәэмин итүгә юнәлгән һәм аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк (2016 елның 28 декабрендәге 27-О номерлы билгеләмә).

Шуның белән дәгъвалана торган нормаларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм алар гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дә ул күрсәткән аспектта конституциячел хокукларын боза торган буларак санала алмыйлар.

Карала торган торак-коммуналь хезмәтне күрсәтүгә килешү аның белән төзелгән булу-булмавын тикшерү, аның төзелүенең законлылыгын бәяләү, шулай ук аның эше буенча чыгарылган хокук куллану карарларының нигезле булу-булмавын тикшерү эшнең факттагы хәлләрен тикшерүне күздә тота, бу исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән компетенциясенә керми.

Мөрәҗәгать итүченең конкрет эшендә үз көченә кермәгән норматив хокукый актның кулланылуы турындагы дәлилгә

килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды шуны билгели: «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң кимендә ун көн узгач үз көченә керәләр (8 статьяның 5 пункты). Күрсәтелгән хокукый җайга салу «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында да чагылыш тапкан, аның 6 статьясы нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керәләр, әгәр дә актларның үзләрендә аларның бүтән, соңрак, үз көченә керү вакыты билгеләнгән булмаса.

Димәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карарының 4 пунктындагы дәгъвалана торган беренче абзацында күрсәтелгән тәгъбир федераль һәм республика законнары нормаларына нигезләнгән.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карарының 4 пунктындагы мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган беренче абзацында аның үзеннән-үзе Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат

алмашу тәртибенең 2, 3 һәм 6 пунктлары, гамәлгә кертү тәртибе буенча тулысынча аталган карар, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карарының 4 пунктындагы беренче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка В.М. Омарова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка В.М. Омаровага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 14-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**о прекращении производства по жалобе гражданки А.Ф. Сабитовой на нарушение конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 5 декабря 2015 года № 100-ЗРТ)**

13 июля
2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании сообщение судьи Л.В. Кузьминой о прекращении производства по жалобе гражданки А.Ф. Сабитовой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка А.Ф. Сабитова, действующая в интересах недееспособной гражданки Г.М. Сабитовой, с жалобой на нарушение конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 5 декабря 2015 года № 100-ЗРТ).

Конституционный суд Республики Татарстан принял данную жалобу к рассмотрению (определение от 19 июня 2018 года № 6-О).

22 июня 2018 года гражданка Г.М. Сабитова умерла (запись акта о смерти № 173 от 22 июня 2018 года в Отделе ЗАГС исполнительного комитета Балтасинского муниципального района Республики Татарстан), о чем Конституционный суд Республики Татарстан был уведомлен 9 июля 2018 года.

2. В соответствии со статьей 63 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан прекращает производство по делу в случаях, если в ходе заседания будут выявлены основания к отказу в принятии обращения к рассмотрению.

Согласно пункту 1 части 1 статьи 29 Федерального закона от 24 апреля 2008 года № 48-ФЗ «Об опеке и попечительстве» опека прекращается в случае смерти подопечного. Поскольку смерть подопечного является безусловным основанием к отказу в принятии жалобы его опекуна к рассмотрению, производство по жалобе гражданки А.Ф. Сабитовой подлежит прекращению.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 63 и частью первой статьи 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Прекратить производство по жалобе гражданки А.Ф. Сабитовой на нарушение конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в

Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 5 декабря 2015 года № 100-ЗРТ) в связи со смертью лица, в интересах которого действовала заявительница.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке А.Ф. Сабитовой и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 15-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 8.2 статьясындагы 1 пункты белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында**

2018 ел
13 июль
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында судья Л.В. Кузьмина мәгълүматын тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына хокуктан файдалануга сәләтсез гражданка Г.М. Сабитова мәнфәгатьләрендә эш итүче гражданка Ә.Ф. Сабитова «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 8.2 статьясындагы 1 пункты белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге шикаятьне карауга кабул итте (2018 елның 19 июнендәге 6-О номерлы билгеләмә).

2018 елның 22 июнендә гражданка Г.М. Сабитова вафат булган (Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты ГХАТ бүлегенең 2018 елның 22 июнендәге 173 номерлы үлү турында акт язмасы), бу хакта Татарстан Республикасы Конституция судына 2018 елның 9 июлендә хәбәр ителде.

